Шәдке авыл җирлеге чиге Үзәк авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Шәдке, Үзәк һәм Олы Нырсы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кече Мирәтәк авылыннан 1,0 км төньяк-көнбатышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасыннан алып 600 м төньяк-көнбатышка таба «Кызыл Йолдыз урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Теләче участок урманчылыгында-гы 23 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 1,4 км төньякка таба 23 нче, 22 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап, сынык сызык ясап, 3,8 км көньяк-көнбатышка таба 22, 26, 27 нче урман кварталларының көньяк, көньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 2,4 км төньяк-көнбатышка таба 27 нче, 25 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 450 м көнчыгышка таба урман полосасының көньяк чиге буйлап Шәдке, Үзәк авыл җирлекләре һәм Питрәч муниципаль районы чикләре тоташкан урында Шәдке авылыннан 2,4 км төньякта урнашкан 27 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Шәдке авыл җирлеге чиге Олы Нырсы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Шәдке, Олы Нырсы авыл җирлекләре һәм Балык Бистәсе муниципаль районы чикләре тоташкан урында Олы Нырсы авылыннан 4,6 км көньякта урнашкан 21 нче тоташу ноктасыннан алып 800 м төньяк-көнбатышка таба «Кызыл Йолдыз урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Арыш участок урманчылыгындагы 49 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 950 м көньяк-көнбатышка таба 49 нчы, 48 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап бара, аннары төньякка таба 200 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 2,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, инешкә кадәр бара, 400 м инеш агымы буенча аска таба аңа кибеп баручы инеш койган җиргә кадәр уза, 300 м кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м төньяк-көнбатышка таба, 1,3 км төньякка таба, Нырсы елгасын һәм чокырны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,6 км кабат төньяк-көнбатышка таба, 550 м төньякка таба урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 18 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Шәдке авыл җирлеге чиге Балык Бистәсе муниципаль районы белән чиктәш җирдә 21 нче тоташу ноктасыннан алып Теләче муниципаль районы чиге буйлап Шәдке авыл җирлеге, Балык Бистәсе һәм Питрәч муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Шәдке авылыннан 3,9 км көнбатышта урнашкан 28 нче (55 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Шәдке авыл җирлеге чиге Питрәч муниципаль районы белән чиктәш җирдә 28 нче (55 нче) тоташу ноктасыннан алып Теләче муниципаль районы чиге буйлап 27 нче тоташу ноктасына кадәр уза.».

## 1382. Аерым муниципаль берәмлекләр территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Алексеевск муниципаль районы составына керүче түбәндәге муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртергә:

1) әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы»ның һәм «Лебяжье авыл җирлеге»нең;

2) әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә «Сахаровка авыл җирлеге»нең һәм «Кыр Шонталысы авыл җирлеге»нең.

**2 статья**

«Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 11-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш) әлеге Законга 3 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 30 декабре
№ 147-ТРЗ

Үзгәрешләрне исәпкә алып,
муниципаль берәмлекләр чикләре
**карта-схемасы**

«Аерым муниципаль берәмлекләр территорияләре чикләрен үзгәртү
һәм «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең
һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта




Шартлы билгеләр

- Алексеевск муниципаль районы чиге
- муниципаль берәмлекләр чикләре
-А-Б - Лебяжье авыл җирлегенең һәм "Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлегенең чиктәш чиге
- җирлекләрнең административ үзәкләре
- торак пунктлар
- Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге территориясе составына кертелә торган Алексеевск муниципаль районының "Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге территориясе

«Аерым муниципаль берәмлекләр территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

Үзгәрешләрне исәпкә алып, муниципаль берәмлекләр чикләре
**карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

- Алексеевск муниципаль районы чиге
- муниципаль берәмлекләр чикләре
- А-Б - Кыр Шонталысы авыл җирлегенең һәм Сахаровка авыл җирлегенең чиктәш чиге
- җирлекләрнең административ үзәкләре
- торак пунктлар
- Алексеевск муниципаль районының Сахаровка авыл җирлеге территориясе составына кертелә торган Алексеевск муниципаль районының Кыр Шонталысы авыл җирлеге территориясе
- Алексеевск муниципаль районының Кыр Шонталысы авыл җирлеге территориясе составына кертелә торган Алексеевск муниципаль районының Сахаровка авыл җирлеге территориясе

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен үзгәртү
һәм «Алексеевск муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
үзгәрешләр кертү хакында»
Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

**«Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 11-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кертелә торган үзгәрешләр**

1 — 22 нче кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Алексеевск муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм
аларның статусы турында" Татарстан
Республикасы Законына
1 нче кушымта

# "Алексеевск муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре

## **карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

- муниципаль район чиге
29 - тоташу ноктасының тәртип саны
10 - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлекнең административ үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | | |
|---|---|---|
| *4(57) - 8(58)* | - | Балык Бистәсе муниципаль районы |
| *8(58) - 36(81)* | - | Чистай муниципаль районы |
| *36(81) - 44(29)* | - | Аксубай муниципаль районы |
| *44(29) - 42(30)* | - | Нурлат муниципаль районы |
| *42(30) - 18(31)* | - | Әлки муниципаль районы |
| *18(31) - 1(32)* | - | Спас муниципаль районы |
| *1(32) - 4(57)* | - | Лаеш муниципаль районы |

## «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы |
| 2 | Биләр авыл җирлеге |
| 3 | Зур Полянка авыл җирлеге |
| 4 | Зур Тигәнәле авыл җирлеге |
| 5 | Бутлеровка авыл җирлеге |
| 6 | Войкино авыл җирлеге |
| 7 | Зирекле авыл җирлеге |
| 8 | Кыркүл авыл җирлеге |
| 9 | Көрнәле авыл җирлеге |
| 10 | Лебедино авыл җирлеге |
| 11 | Лебяжье авыл җирлеге |
| 12 | Левашево авыл җирлеге |
| 13 | Майна авыл җирлеге |
| 14 | Урманасты Шонталысы авыл җирлеге |
| 15 | Родники авыл җирлеге |
| 16 | Ромодан авыл җирлеге |
| 17 | Сахаровка авыл җирлеге |
| 18 | Урта Тигәнәле авыл җирлеге |
| 19 | Кыр Шонталысы авыл җирлеге |
| 20 | Ялкын авыл җирлеге |

«Алексеевск муниципаль районы»<br>муниципаль берәмлегенең һәм аның<br>составындагы муниципаль берәмлекләрнең<br>территорияләре чикләрен билгеләү<br>һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>2 нче кушымта

## «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Алексеевск муниципаль районы» һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

«Алексеевск муниципаль районы» Лаеш, Балык Бистәсе, Чистай, Аксубай, Нурлат, Әлки һәм Спас муниципаль районнары белән чиктәш.

«Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Алексеевск, Нурлат һәм Аксубай муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Шама авылыннан 10,0 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 44 нче (29 нчы) тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 100 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Биләр участок урманчылыгындагы 62 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, көнбатышка таба 7,9 км «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Биләр участок урманчылыгындагы 62, 61, 60, 58, 57, 56 нчы урман кварталларының көньяк чиге буйлап, Биләр – Көрнәле Әмзә автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Дуңгыз инешенә кадәр үтә, әлеге инеш агымы буенча аска таба 2,7 км, төньякка таба 50 м агач-куак массивының көнчыгыш чиге буйлап, төньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 450 м 65 нче, 91 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап, төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, сынык сызык ясап, көнбатышка таба 300 м 91 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, төньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 400 м 91 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре

буйлап, сынык сызык ясап, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м 91 нче, 90 нчы урман кварталларының көньяк һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап, көнбатышка таба 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 450 м 90 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 300 м 87 нче, 89 нчы урман кварталларының көньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 50 м 89 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 600 м 89 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап, көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 300 м 89 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап, көньякка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 550 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман массивының көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман массивының көнбатыш чиге буйлап, 150 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 650 м һәм көнбатышка таба 500 м, урман полосасының төньяк чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, урман полосасының төньяк чиге буйлап 350 м, агач-куак массивының көньяк чиге буйлап 150 м, урман полосасының төньяк чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 800 м, урман полосасының төньяк чиге буйлап 150 м, урман полосасы буйлап 150 м Алексеевск, Нурлат һәм Әлки муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Мораса авылыннан 1,6 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 42 нче (30 нчы) тоташу ноктасына кадәр бара.

«Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Алексеевск, Әлки һәм Спас муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Караваево авылыннан 4,8 км көньяк-көнбатышта урнашкан 18 нче (31 нче) тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 1,6 км, төньяк-көнчыгышка таба 900 м, алга таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,9 км уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, үләт чокырының төньяк чиге буйлап 150 м, «Алексеевск — Югары Колок» — Демидовка — Хлебодаровка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, яңадан авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,0 км Салман елгасына кадәр уза, аннары, Алексеевск — Югары

Колок автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, шушы елга агымы буенча аска таба 1,3 км аның Актай елгасына койган җиренә кадәр уза, Актай елгасы агымы буенча өскә таба 4,6 км бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 900 м уза, 350 м урман полосасы буйлап, 950 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м урман полосасы буйлап, 550 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, көнчыгышка таба 1,1 км урман полосасының көньяк чиге буйлап, көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 1,5 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 750 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 2,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Зур Алан участок урманчылыгындагы 77 нче, 78 нче урман кварталларының төньяк һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 1,9 км, сынык сызык ясап, «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 89 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап төньякка таба 1,7 км һәм төньяк чиге буйлап көнчыгышка таба 950 м уза, сынык сызык ясап, «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Зур Алан участок урманчылыгындагы 80 нче, 81 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 1,9 км бара, алга таба, сынык сызык ясап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 81, 80, 79 нчы урман кварталларының көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 2,6 км уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 1,7 км инешкә кадәр бара, инеш агымы буенча аска таба 700 м уза, аннары, сынык сызык ясап, көнчыгышка таба 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, көньякка таба, сынык сызык ясап, 1,6 км 49 нчы, 50 нче урман кварталларының көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Зур Алан участок урманчылыгындагы 53 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м Чаллы елгасына кадәр уза, аннары әлеге елга агымы буенча өскә таба 550 м аңа коя торган кибеп баручы инеш тамагына кадәр бара, алга таба әлеге инеш агымы буенча өскә таба 1,4 км, көньяк-көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман массивының төньяк чиге буйлап, көньякка таба 250 м 51 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап һәм,

сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 1,5 км көньяк һәм көнчыгыш чикләре буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, көньякка таба 4,3 км 54, 61, 67, 73 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң 700 м көнчыгышка таба 73 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, алга таба әлеге инеш агымы буенча аска таба 2,3 км, көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 950 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 450 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Зур Алан участок урманчылыгындагы 113 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап, көньяк-көнбатышка таба 30 м урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 2,6 км бара, алга таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 450 м, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 350 м уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 900 м, «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Базарлы Матак участок урманчылыгындагы 21 нче, 22 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап 2,3 км бара, шуннан соң көньякка таба 700 м 22 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, төньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба урман полосасының көньяк чиге буйлап 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 400 м уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, текә ярлы участокны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 3,6 км Кече Чирмешән елгасына кадәр бара, шушы елга агымы буенча аска таба 2,5 км уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 2,8 км урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба, Мораса авылын Базарлы Матак – Мамык автомобиль юлы белән тоташтыручы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 42 нче (30 нчы) тоташу ноктасына кадәр бара.

«Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 18 нче (31 нче) тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка таба 1,6 км, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 3,5 км, көнбатышка таба 950 м, төньяк-көнбатышка таба 550 м, төньяк-көнчыгышка

таба 6,2 км, төньяк-көнбатышка таба 450 м уза, аннары күл буенча 100 м бара, алга таба яңадан авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка таба 300 м һәм, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба Актай елгасына кадәр 700 м уза, аннары әлеге елга агымы буенча аска таба 3,7 км, авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка, текә ярлы участокларны, чокырларны һәм Актай елгасын кисеп үтеп, 3,2 км уза, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буенча 250 м, «Болгар урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 6 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буенча 950 м уза, алга таба, сынык сызык ясап, 2 нче, 3 нче урман кварталларының көньяк чиге буенча көнчыгышка таба 2,1 км бара, аннары, сынык сызык ясап, 3 нче урман кварталының көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буенча төньяк-көнбатышка таба 2,1 км уза, алга таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча Алексеевск, Спас һәм Лаеш муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Березовая Грива авылыннан 7,7 км төньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 1 нче (32 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 1 нче (32 нче) тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап Алексеевск, Лаеш һәм Балык Бистәсе муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Балахчино авылыннан 6,8 км төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 4 нче (57 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 4 нче (57 нче) тоташу ноктасыннан алып көнчыгышка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап Алексеевск, Балык Бистәсе һәм Чистай муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Речной авылыннан 4,7 км төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 8 нче (58 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 8 нче (58 нче) тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 7,8 км Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча, 3,7 км Шентала елгасы агымы буенча өскә таба уза, шуннан соң, чокырны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 700 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, сынык

сызык ясап, 750 м «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Чистай участок урманчылыгындагы 5 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары, Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм юл буе урман полосасын кисеп үтеп, 300 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 800 м 6 нчы урман кварталының көнбатыш, көньяк-көнбатыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап, 350 м урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,0 км көньяк-көнбатышка таба буаның сул яры буйлап бара, алга таба 2,6 км Бахта елгасы агымы буенча өскә таба, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 900 м көнбатышка таба, 3,2 км көньяк-көнбатышка таба, 350 м көньяк-көнчыгышка таба, 400 м көньяк-көнбатышка таба уза, 100 м агач-куак полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м агач-куак полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м агач-куак полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,4 км көньяк-көнчыгышка таба һәм 150 м көньяк-көнбатышка таба уза, 800 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр бара, 600 м әлеге инеш агымы буенча аска таба уза, алга таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 100 м көньяк-көнчыгышка таба чокыр буенча бара, аннары, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 650 м көньяк-көнчыгышка таба, 2,7 км төньяк-көнчыгышка таба, 1,2 км көньяк-көнчыгышка таба, 2,4 км көньяк-көнбатышка таба, 700 м көньякка таба, 250 м көньяк-көнбатышка таба кибеп баручы инешкә кадәр уза, 2,9 км әлеге инеш агымы буенча аска таба аның Шенталка елгасына койган җиренә кадәр бара, 1,0 км әлеге елга агымы буенча өскә таба уза, алга таба, сынык сызык ясап, Шенталка елгасының текә ярын кисеп үтеп, 3,7 км көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, төньяк-көнчыгышка таба 300 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Баганалы участок урманчылыгындагы 56 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап, 800 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 1,9 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, 1,8 км әлеге инеш агымы буенча аска таба аның Шенталка елгасына койган җиренә кадәр бара, 2,8 км әлеге елга агымы буенча өскә

таба әлеге елгага коя торган кибеп баручы инеш тамагына кадәр уза, 450 м әлеге инеш агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м урман утыртмаларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,8 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 139 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 800 м көньякка таба һәм көньяк чиге буйлап 750 м көнчыгышка таба уза, аннары 100 м төньяк-көнчыгышка таба күл буенча, 450 м көньяк-көнчыгышка таба 139 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң көнчыгышка таба 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман утыртмаларының көньяк чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м 139 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба 84 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 300 м көнчыгышка таба һәм көнчыгыш чиге буйлап 700 м көньяк-көнбатышка таба, 100 м көньяк-көнчыгышка таба урман утыртмаларының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 400 м 84 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 50 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң 600 м көньяк-көнчыгышка таба 84 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 750 м төньяк-көнчыгышка таба 88 нче, 89 нчы урман кварталларының төньяк чиге буйлап уза, аннары 3,3 км 78, 77, 68 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,9 км көньяк-көнчыгышка таба 69 нчы урман кварталының көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап, 150 м көньяк-көнбатышка таба урман утыртмаларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м һәм көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м көньяк-көнчыгышка таба бара, алга таба, Мөслим – Биләр автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м көньяк-көнчыгышка таба, буаны кисеп үтеп, 200 м төньяк-көнчыгышка таба уза, сынык сызык ясап, 400 м көньяк-көнчыгышка таба 70 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 550 м көнчыгышка таба 70 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 4,6 км көньяк-көнчыгышка таба 80, 81, 93 нче урман кварталларының көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап бара, аннары 200 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буй-

лап, 150 м көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 2,2 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Алексеевск, Чистай һәм Аксубай муниципаль районнарының чикләре тоташкан урында Чуаш Майнасы авылыннан 950 м көнчыгышта Кече Чирмешән елгасында урнашкан X = 394637,75, Y = 1397038,74 координаталы 36 нчы (81 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Аксубай муниципаль районы» белән чиктәш җирдә 44 нче (29 нчы) тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, төньякка таба 6,6 км «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Биләр участок урманчылыгындагы 62, 49, 31, 30, 21 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 3,9 км 21, 20, 19 нчы урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 7,4 км 9, 10, 2, 1 нче урман кварталларының көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап бара, аннары, Кече Чирмешән елгасын кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 6,9 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 73 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 200 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Баганалы участок урманчылыгындагы 150 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 50 м урман утыртмаларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м урман утыртмалары буйлап, 100 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Биләр участок урманчылыгындагы 73 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 1,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман утыртмаларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м Кече Чирмешән елгасына кадәр уза, әлеге елга агымы буенча өскә таба 8,3 км 36 нчы (81 нче) тоташу ноктасына кадәр бара.

«Алексеевск муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

**Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

«Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Бутлеровка, Кыркүл, Көрнәле, Лебедино, Лебяжье, Сахаровка авыл җирлекләре һәм Балык Бистәсе муниципаль районы белән чиктәш.

«Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чиге Балык Бистәсе муниципаль районы белән чиктәш җирдә «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Бутлеровка авыл җирлеге һәм Балык Бистәсе муниципаль районы чикләре тоташкан урында Юеш Көрнәле авылыннан 7,1 км төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 428646,35, Y = 1362839,70 координаталы 5 нче тоташу ноктасыннан алып Алексеевск муниципаль районы чиге буйлап «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Лебяжье авыл җирлеге һәм Балык Бистәсе муниципаль районы чикләре тоташкан урында Сакон авылыннан 9,6 км төньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 433670,00, Y = 1365119,97 координаталы 6 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чиге Лебяжье авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 6 нчы тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 11,5 км Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап аның ярына кадәр уза, алга таба, сынык сызык ясап, Алексеевск — Лебяжье — Сакон автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буй-

лап 950 м һәм көньякка таба 800 м Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр бара, аннары көнбатышка таба 30 м шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буйлап уза, шуннан соң, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньякка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 40 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м, 300 м көнбатышка таба, 1,6 км көньякка таба, урман массивын кисеп үтеп, 1,6 км көньяк-көнчыгышка таба бара, 400 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 450 м урман полосасы буйлап, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Лебяжье һәм Сахаровка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кече Кызылъяр авылыннан 4,8 км төньяк-көнбатышта урнашкан 10 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чиге Сахаровка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 10 нчы тоташу ноктасыннан алып Суходол кибеп баручы инеше агымы буенча өскә таба 6,2 км уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 40 м урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, көньякка таба 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 300 м «Алексеевск урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 16 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Сахаровка һәм Кыркүл авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кыркүл авылыннан 2,9 км төньякта урнашкан 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чиге Кыркүл авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 11 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 300 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 16 нчы урман кварталының көньяк һәм көнбатыш чикләре буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 30 м, инешне һәм Алексеевск – Биләр автомобиль юлына бүлеп бирелгән поло-

саны кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 1,2 км, 350 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 1,8 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 750 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 104 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап бара, кибеп баручы инешнең текә уң ярын кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап шушы инешкә кадәр бара, шушы инеш агымы буенча аска таба 750 м аның Курлянка кибеп баручы инешенә койган җиренә кадәр уза, шуннан соң әлеге инеш агымы буенча өскә таба 850 м бара, аннары, Курлянка кибеп баручы инешенең текә уң ярын кисеп үтеп, көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап урман полосасына кадәр уза, 400 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м урман полосасының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосаларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм 1,5 км көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 350 м 104 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Кыркүл һәм Көрнәле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Спас авылыннан 2,6 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 12 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чиге Көрнәле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 12 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 650 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 37 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Көрнәле һәм Лебедино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Спас авылыннан 2,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 45 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чиге Лебедино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 45 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 350 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 112 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 850 м 112 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш һәм төньяк чикләре буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, ике мәртәбә чокырларны кисеп

үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,2 км төньяк-көнбатышка таба, 900 м төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, берничә мәртәбә чокырларны кисеп үтеп, 1,7 км төньяк-көнбатышка таба 112 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенә кадәр бара, 350 м аның төньяк-көнчыгыш һәм төньяк чикләре буйлап уза, көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 112 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап бара, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 112 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап уза, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 25 м 112 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Лебедино һәм Бутлеровка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Спас авылыннан 650 м төньякта урнашкан 13 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чиге Бутлеровка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 13 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,4 км төньяк-көнчыгышка таба, 150 м төньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 92 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м һәм төньяк-көнбатыш чиге буенча 150 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары төньякка таба 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 1,7 км урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм Курлянка елгасының текә уң ярын кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап шушы елгага кадәр уза, шушы елга агымы буенча аска таба 1,4 км аңа Курлянка инеше койган җиргә кадәр бара, шуннан соң, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,6 км шушы инеш агымы буенча өскә таба уза, аннары, текә ярларны кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап урман полосасына кадәр бара, 600 м аның төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң, яр буе агач-куак полосасын кисеп үтеп, көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, 700 м шушы инеш агымы буенча өскә таба уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң 1,8 км урман полосасы буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м төньяк-көнчыгышка таба,

урман массивын кисеп үтеп, 350 м көнчыгышка таба кибеп баручы инешкә кадәр бара, Алексеевск – Югары Колок автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,2 км шушы инеш агымы буенча аска таба уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 400 м Куйбышев сусаклагычы яры буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 8,5 км Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 5 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Алексеевск муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
4 нче кушымта

**Алексеевск муниципаль районының «Биләр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Биләр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Биләр авыл җирлеге Зирекле, Майна, Урманасты Шонталысы авыл җирлекләре, Аксубай һәм Нурлат муниципаль районнары белән чиктәш.

Биләр авыл җирлеге чиге Аксубай муниципаль районы белән чиктәш җирдә Биләр, Майна авыл җирлекләре һәм Аксубай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Горка авылыннан 3,2 км көнчыгышта Кече Чирмешән елгасында урнашкан 37 нче тоташу ноктасыннан алып Алексеевск муниципаль районы чиге буйлап Биләр авыл җирлеге, Аксубай һәм Нурлат муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Шама авылыннан 10,0 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 44 нче (29 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

Биләр авыл җирлеге чиге Нурлат муниципаль районы белән чиктәш җирдә 44 нче (29 нчы) тоташу ноктасыннан алып Алексеевск муниципаль районы чиге буйлап Биләр, Зирекле авыл җирлекләре һәм Нурлат муниципаль районы чикләре тоташкан урында Гоголиха авылыннан 6,5 км көньяк-көнчыгышта

«Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Биләр участок урманчылыгындагы 65 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш почмагында урнашкан 43 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Биләр авыл җирлеге чиге Зирекле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 43 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 2,9 км «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Биләр участок урманчылыгындагы 65 нче, 64 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап уза, 150 м 76 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 1,7 км 84 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң төньякка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасы буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 900 м, урман массивы буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м һәм төньяк-көнбатышка таба 300 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 700 м урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 750 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, Биләр – Зирекле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм Кече Чирмешән елгасының текә сул ярын кисеп үтеп, 2,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Биләр, Зирекле һәм Урманасты Шонталысы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Приозерная авылыннан 700 м төньякта Кече Чирмешән елгасында урнашкан 39 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Биләр авыл җирлеге чиге Урманасты Шонталысы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 39 нчы тоташу ноктасыннан алып Кече Чирмешән елгасы агымы буенча өскә таба 2,9 км уза, шуннан соң 1,5 км шушы елганың кибеп баручы ермагы буенча елга агымы буйлап өскә таба күлгә кадәр бара, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 200 м күл буйлап уза, аннары 150 м яңадан Кече Чирмешән елгасының кибеп баручы ермагы буенча елга агымы буйлап өскә таба Кече Чирмешән елгасының төп үзәненә кадәр бара, 4,9 км шушы елга агымы буенча өскә таба «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Биләр участок урманчылыгындагы 92 нче урман кварталына кадәр уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньякка таба 700 м 92 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш, көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап бара, төньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап,

50 м урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, төньякка таба 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Биләр, Урманасты Шонталысы һәм Майна авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Арбузов-Баран авылыннан 1,5 км көнчыгышта урнашкан 38 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Биләр авыл җирлеге чиге Майна авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 38 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Алексеевск – Биләр автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 3,0 км шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м агач-куак массивы буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, 1,5 км аның агымы буенча аска таба Кече Чирмешән елгасына кадәр уза, шуннан соң, Мөслим – Биләр автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 7,5 км шушы елга агымы буенча өскә таба 37 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Алексеевск муниципаль районы»<br>муниципаль берәмлегенең һәм аның<br>составындагы муниципаль берәмлекләрнең<br>территорияләре чикләрен билгеләү<br>һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>5 нче кушымта

## Алексеевск муниципаль районының «Зур Полянка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Зур Полянка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Зур Полянка авыл җирлеге Зур Тигәнәле, Зирекле, Урманасты Шонталысы, Родники, Ромодан авыл җирлекләре һәм Әлки муниципаль районы белән чиктәш.

Зур Полянка авыл җирлеге чиге Ромодан авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Зур Полянка, Ромодан авыл җирлекләре һәм Әлки муниципаль районы чикләре тоташкан урында Савинский поселогыннан 2,6 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 300 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 125 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 125 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 125 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 20 м төньяк-көнчыгышка таба һәм төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м көньяк-көнчыгышка таба бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 125 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м көньяк-көнчыгышка таба, 700 м төньяк-көнчыгышка таба Зур Полянка, Ромодан һәм Зур Тигәнәле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Александровка авылыннан 2,7 км төньяк-көнбатышта урнашкан 24 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Зур Полянка авыл җирлеге чиге Зур Тигәнәле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 24 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 800 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Зур Полянка участок урманчылыгындагы 36 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, төньяк-көнчыгышка таба 1,4 км 36 нчы, 35 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 1,1 км 37 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап бара, төньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, төньяк-көнбатышка таба 1,0 км 37 нче урман кварталының көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 350 м 102 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, 2,4 км 38 нче, 39 нчы урман кварталларының төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, Алексеевск – Биләр автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм ике мәртәбә кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 2,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 16 нчы урман кварталына кадәр,

20 м 16 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап буага кадәр бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 100 м буаның уң яры буйлап аңа Баранка елгасы койган җиргә кадәр бара, 650 м әлеге елга агымы буенча өскә таба шушы елгага коя торган инешкә кадәр уза, 1,2 км аның агымы буенча өскә таба 99 нчы урман кварталына кадәр бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 300 м шушы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,2 км 99 нчы, 100 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап Зур Полянка, Зур Тигәнәле, Родники авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кызыл Чишмә авылыннан 2,9 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 33 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Зур Полянка авыл җирлеге чиге Родники авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 33 нче тоташу ноктасыннан алып, урман массивын кисеп үтеп, көнчыгышка таба 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Зур Полянка участок урманчылыгындагы 105 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 800 м һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 30 м уза, аннары 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км 105 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Зур Полянка, Родники һәм Урманасты Шонталысы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Зур Полянка авылыннан 3,9 км төньяк-көнчыгышта 18 нче урман кварталының көнбатыш почмагында урнашкан 34 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Зур Полянка авыл җирлеге чиге Урманасты Шонталысы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 34 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 3,2 км «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Зур Полянка участок урманчылыгындагы 18, 20, 23 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 1,3 км 23 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап бара, аннары, инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка

таба 1,2 км, көньяк-көнбатышка таба 550 м, көньяк-көнчыгышка таба 250 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Баганино участок урманчылыгындагы 115 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш почмагына кадәр уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 950 м шушы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары көньякка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Сары елгасына кадәр уза, 2,7 км аның агымы буенча аска таба «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Зур Полянка участок урманчылыгындагы 109 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш почмагына кадәр бара, шуннан соң көнбатышка таба 30 м шушы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 2,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 700 м профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап Алексеевск – Биләр автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр уза, аны кисеп үтә, 250 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 46 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш почмагына кадәр бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 450 м шушы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, агач-куак массивын кисеп үтеп, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Баранка елгасына кадәр уза, 1,7 км аның агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң, яр буе агач-куак полосасын кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м сазлыкның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 550 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м көньяк-көнбатышка таба, 500 м көньяк-көнчыгышка таба бара, 850 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м көньяк-көнчыгышка таба, 250 м көньяк-көнбатышка таба бара, 1,1 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м көньяк-көнбатышка таба, 200 м көньякка таба 59 нчы урман кварталына кадәр бара, 300 м аның көнчыгыш чиге буйлап Зур Полянка, Урманасты Шонталасы һәм Зирекле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Красный Баран авылыннан 3,9 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 40 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Зур Полянка авыл җирлеге чиге Зирекле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 40 нчы тоташу ноктасыннан алып «Биләр

урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Зур Полянка участок урманчылыгындагы 59 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап көнбатышка таба 1,2 км һәм көнбатыш чиге буйлап төньякка таба 250 м бара, шуннан соң, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, көнбатышка таба 6,1 км 58, 57, 56, 55, 54 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап Зур Полянка, Зирекле авыл җирлекләре һәм Әлки муниципаль районы чикләре тоташкан урында Александровка авылыннан 3,7 км көньякта 61 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш почмагында урнашкан 41 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Зур Полянка авыл җирлеге чиге Әлки муниципаль районы белән чиктәш җирдә 41 нче тоташу ноктасыннан алып Алексеевск муниципаль районы чиге буйлап 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Алексеевск муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
6 нчы кушымта

**Алексеевск муниципаль районының «Зур Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Зур Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Зур Тигәнәле авыл җирлеге Зур Полянка, Көрнәле, Родники, Ромодан һәм Урта Тигәнәле авыл җирлекләре белән чиктәш.

Зур Тигәнәле авыл җирлеге чиге Урта Тигәнәле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Зур Тигәнәле, Урта Тигәнәле һәм Көрнәле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Коры Көрнәле авылыннан 1,3 км көнчыгышта урнашкан 25 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, чокырны кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, 1,6 км шушы инеш агымы буенча өскә таба уза, аннары, кибеп баручы инешнең

текә уң ярын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м төньяк-көнчыгышка таба, чокырны кисеп үтеп, 450 м көньяк-көнчыгышка таба урман полосасына кадәр бара, 950 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, төньяк-көнчыгышка таба 1,1 км бара, аннары көнчыгышка таба 650 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, Алексеевск – Биләр автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң, кибеп баручы инешне һәм Сахаровка – Зур Тигәнәле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 2,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 50 м плотинаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, Тигәнәле елгасын һәм аның текә ярларын кисеп үтеп, 3,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Зур Полянка участок урманчылыгындагы 92 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш почмагына кадәр бара, көнчыгышка таба 200 м шушы урман кварталының төньяк чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Зур Тигәнәле, Урта Тигәнәле һәм Родники авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Родники авылыннан 1,8 км көньяк-көнбатышта урнашкан 32 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Зур Тигәнәле авыл җирлеге чиге Родники авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 32 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Зур Полянка участок урманчылыгындагы 92 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап көнчыгышка таба 150 м һәм көнчыгыш чиге буйлап 250 м көньяк-көнбатышка таба уза, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, сынык сызык ясап, көньякка таба 850 м 92 нче, 3 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап уза, көньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, сынык сызык ясап, көньякка таба 1,7 км 3, 4, 95, 96 нчы урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м уза, 1,6 км 96, 98, 100 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап Зур Тигәнәле, Родники һәм Зур Полянка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кызыл Чишмә авылыннан 2,9 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 33 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Зур Тигәнәле авыл җирлеге чиге Зур Полянка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Зур Тигәнәле, Зур Полянка һәм Ромодан авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Александров-

ка авылыннан 2,7 км төньяк-көнбатышта урнашкан 24 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 800 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Зур Полянка участок урманчылыгындагы 36 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, төньяк-көнчыгышка таба 1,4 км 36 нчы, 35 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 1,1 км 37 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап уза, төньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, төньяк-көнбатышка таба 1,0 км 37 нче урман кварталының көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 350 м 102 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, 2,4 км 38 нче, 39 нчы урман кварталларының төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, Алексеевск – Биләр автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм ике мәртәбә кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 2,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 16 нчы урман кварталына кадәр, 20 м 16 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап буага кадәр бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 100 м буаның уң яры буйлап аңа Баранка елгасы койган җиргә кадәр уза, 650 м әлеге елга агымы буенча өскә таба шушы елгага коя торган инешкә кадәр бара, 1,2 км аның агымы буенча өскә таба 99 нчы урман кварталына кадәр уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 300 м шушы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,2 км 99 нчы, 100 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 33 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Зур Тигәнәле авыл җирлеге чиге Ромодан авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 24 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 350 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Зур Полянка участок урманчылыгындагы 36 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 40 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 100 м, сынык сызык ясап, 1,1 км 36 нчы, 35 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап уза, сынык сызык ясап, көнбатышка таба 650 м 34 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м көньяк-көнбатышка таба, 50 м көньяк-көнчыгышка таба уза, сынык сызык ясап, 34 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш

чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 250 м һәм көньяк чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 50 м инешкә кадәр бара, 350 м инеш агымы буенча аска таба буага кадәр уза, 50 м төньяк-көнбатышка таба буаның уң яры буйлап плотинага кадәр бара, көньякка таба 30 м плотинаның көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары, плотинаны кисеп үтеп, көнбатышка таба 10 м, шуннан соң 550 м кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба аның Ромодан елгасына койган җиренә кадәр бара, аннары 4,5 км шушы елга агымы буенча аска таба Ромодан елгасына коя торган инешкә кадәр уза, шушы инеш агымы буенча өскә таба 1,4 км бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м төньяк-көнбатышка таба, 250 м төньяк-көнчыгышка таба уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 40 м 10 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң төньякка таба 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 700 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 79 нчы урман кварталына кадәр уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 450 м шушы урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, төньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 79 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап 200 м һәм көнбатыш чиге буйлап төньякка таба 100 м уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 79 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, сынык сызык ясап, 79 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м Зур Тигәнәле, Ромодан һәм Көрнәле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Масловка авылыннан 2,0 км көнчыгышта урнашкан 22 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Зур Тигәнәле авыл җирлеге чиге Көрнәле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 22 нче тоташу ноктасыннан алып көнчыгышка таба 1,1 км «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 79 нчы, 80 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап уза, шуннан соң 77 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап төньякка таба 600 м һәм төньяк чиге буйлап көнчыгышка таба 1,1 км уза, аннары, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 750 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Зур Полянка участок урманчылыгындагы 6 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап,

50 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 75 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң, урман массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м төньяк-көнбатышка таба, яңадан шушы урман массивын кисеп үтеп, 150 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары төньякка таба 100 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Зур Полянка участок урманчылыгындагы 6 нчы урман кварталы буйлап Каратун кибеп баручы инешенә кадәр уза, шушы инеш агымы буенча аска таба 2,2 км буага кадәр бара, төньяк-көнчыгышка таба 1,0 км буа буйлап бара, аннары 1,6 км Каратун кибеп баручы инеше агымы буенча аска таба уза, шуннан соң, әлеге инешнең текә уң ярын кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 25 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Алексеевск муниципаль районы»<br>муниципаль берәмлегенең һәм аның<br>составындагы муниципаль берәмлекләрнең<br>территорияләре чикләрен билгеләү<br>һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>7 нче кушымта

## Алексеевск муниципаль районының «Бутлеровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Бутлеровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Бутлеровка авыл җирлеге Лебедино авыл җирлеге, «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Лаеш һәм Балык Бистәсе муниципаль районнары белән чиктәш.

Бутлеровка авыл җирлеге чиге «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Бутлеровка авыл җирлеге, «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге һәм Лебедино авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Яңа Спас авылыннан 650 м төньякта

урнашкан 13 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,4 км төньяк-көнчыгышка таба, 150 м төньяк-көнбатышка таба бара, аннары «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 92 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м һәм төньяк-көнбатыш чиге буенча 150 м төньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң төньякка таба 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 1,7 км урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм елганың текә уң ярын кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Курлянка елгасына кадәр бара, шушы елга агымы буенча аска таба 1,4 км аңа Курлянка инеше койган җиргә кадәр уза, аннары, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,6 км шушы инеш агымы буенча өскә таба, шуннан соң, текә ярларны кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап урман полосасына кадәр уза, 600 м аның төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары, яр буе агач-куак полосасын кисеп үтеп, көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, 700 м шушы инеш агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 1,8 км урман полосасы буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м төньяк-көнчыгышка таба, урман массивын кисеп үтеп, 350 м көнчыгышка таба кибеп баручы инешкә кадәр уза, Алексеевск — Югары Колок автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,2 км шушы инеш агымы буенча аска таба бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 400 м Куйбышев сусаклагычы яры буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 8,5 км Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап Бутлеровка авыл җирлеге, «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге һәм Балык Бистәсе муниципаль районы чикләре тоташкан урында Юеш Көрнәле авылыннан 7,1 км төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 428646,35, Y = 1362839,70 координаталы 5 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Бутлеровка авыл җирлеге чиге Лебедино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 13 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 250 м, төньяк-көнбатышка таба 400 м бара, шуннан соң көньякка таба 30 м чокыр төбе буйлап кибеп баручы инешнең чишмә башына кадәр уза, аның агымы буенча аска таба 250 м аның Көрнәле

елгасына койган җиренә кадәр бара, шушы елга агымы буенча аска таба 1,9 км инешнең елгага койган җиренә кадәр бара, Алексеевск – Югары Колок автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, шушы инеш агымы буенча өскә таба 2,4 км уза, аннары көнбатышка таба 200 м урман массивының төньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м һәм төньяк-көнбатышка таба 1,7 км «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 103 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенә кадәр бара, 150 м шушы аерымланган кишәрлекнең көньяк-көнбатыш чиге буйлап, чокырны кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 19 нчы урман кварталының көнчыгыш почмагына кадәр уза, 100 м шушы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Куйбышев сусаклагычына кадәр бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 14,8 км Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап Бутлеровка, Лебедино авыл җирлекләре һәм Лаеш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Балахчино авылыннан 12,7 км төньяк-көнбатышта шушы сусаклагыч акваториясендә урнашкан 3 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Бутлеровка авыл җирлеге чиге Лаеш муниципаль районы белән чиктәш җирдә 3 нче тоташу ноктасыннан алып Алексеевск муниципаль районы чиге буйлап Бутлеровка авыл җирлеге, Лаеш һәм Балык Бистәсе муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Балахчино авылыннан 6,8 км төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 4 нче (57 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Бутлеровка авыл җирлеге чиге Балык Бистәсе муниципаль районы белән чиктәш җирдә 4 нче (57 нче) тоташу ноктасыннан алып Алексеевск муниципаль районы чиге буйлап 5 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Алексеевск муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
8 нче кушымта

**Алексеевск муниципаль районының «Войкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Войкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Войкино авыл җирлеге Лебедино, Левашево, Ялкын авыл җирлекләре, Лаеш һәм Спас муниципаль районнары белән чиктәш.

Войкино авыл җирлеге чиге Лебедино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Войкино, Лебедино авыл җирлекләре һәм Лаеш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Березовая Грива авылыннан 7,6 км төньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 2 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 7,3 км Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап аның ярына кадәр бара, шуннан соң көньякка таба 250 м Куйбышев сусаклагычы яры буйлап «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 29 нчы урман кварталына кадәр уза, сынык сызык ясап, чокырны кисеп үтеп, шушы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 3,2 км һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 350 м бара, текә ярны кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м 29 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м бара, шуннан соң 29 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 200 м һәм көньяк чиге буйлап көнбатышка таба 250 м уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 35 м 30 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 40 м 30 нчы урман кварталының

төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң көнчыгышка таба 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 250 м 30 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, 30 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 100 м һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 200 м бара, шуннан соң 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, төньяк-көнбатышка таба 900 м 30 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 150 м 31 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м уза, сынык сызык ясап, 350 м 31 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м бара, аннары 31 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м һәм, сынык сызык ясап, көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 750 м бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 31 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 550 м көньякка таба һәм көньяк чиге буйлап 300 м көнбатышка таба бара, шуннан соң урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 1,2 км һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 650 м, чокырларны кисеп үтеп, 950 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 350 м һәм көньяк чиге буйлап көнчыгышка таба 1,4 км уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м көнчыгышка таба һәм 100 м көньяк-көнбатышка таба чокырга кадәр бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 300 м чокырның көнчыгыш чиге буйлап уза, сынык сызык ясап, көньякка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап башка чокырга кадәр бара, көньяк-көнчыгышка таба 150 м аның көньяк-көнбатыш чиге буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, 1,5 км аның агымы буенча аска таба башка кибеп баручы инеш тамагына кадәр бара, шуннан соң 2,1 км шушы инеш агымы буенча өскә таба буага кадәр уза, буа плотинасын кисеп үтә һәм көнчыгышка таба 50 м буаның уң яры буйлап бара, аннары 500 м кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 42 нче урман кварталына кадәр бара, шушы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 1,1 км һәм төньяк чиге буйлап көнчыгышка таба 800 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м уза, аннары, сынык сызык ясап, 43 нче

урман кварталының төньяк чиге буйлап көнчыгышка таба 500 м һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 1,0 км бара, шуннан соң, урман массивын кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр, Войкино, Лебедино һәм Левашево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Левашево авылыннан 2,1 км төньяк-көнбатышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Войкино авыл җирлеге чиге Левашево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 15 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 250 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 43 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м 43 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м 43 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 250 м 116 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 119 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 200 м 45 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 45 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 45 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 200 м 45 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 40 м 45 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 150 м бара, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м 45 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, «Алексеевск – Югары Колок» – Бәзәкә – Тукай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Войкино, Левашево һәм Ялкын авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Левашево авылыннан 3,2 км көньяк-көнбатышта урнашкан 16 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Войкино авыл җирлеге чиге Ялкын авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 16 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,5 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап «Биләр ур-

манчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 56 нчы урман кварталына кадәр уза, аннары, сынык сызык ясап, көньякка таба 2,2 км 56 нчы, 57 нче урман кварталлары буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Актай елгасын кисеп үтеп, 50 м комлык буйлап, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 1,3 км урман полосасы буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,0 км урман полосасы буйлап, 400 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Войкино, Ялкын авыл җирлекләре һәм Спас муниципаль районы чикләре тоташкан урында Войкино авылыннан 4,7 км көньякта урнашкан 17 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Войкино авыл җирлеге чиге Спас муниципаль районы белән чиктәш җирдә 17 нче тоташу ноктасыннан алып Алексеевск муниципаль районы чиге буйлап Войкино авыл җирлеге, Спас һәм Лаеш муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Березовая Грива авылыннан 7,7 км төньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 1 нче (32 нче) тоташу ноктасына кадәр бара.

Войкино авыл җирлеге чиге Лаеш муниципаль районы белән чиктәш җирдә 1 нче (32 нче) тоташу ноктасыннан алып Алексеевск муниципаль районы чиге буйлап 2 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Алексеевск муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
9 нчы кушымта

## Алексеевск муниципаль районының «Зирекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Зирекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең террито-

рияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Зирекле авыл җирлеге Биләр, Зур Полянка, Урманасты Шонталысы авыл җирлекләре, Әлки һәм Нурлат муниципаль районнары белән чиктәш.

Зирекле авыл җирлеге чиге Зур Полянка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Зирекле, Зур Полянка һәм Урманасты Шонталысы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Красный Баран авылыннан 3,9 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 40 нчы тоташу ноктасыннан алып «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Зур Полянка участок урманчылыгындагы 59 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап көнбатышка таба 1,2 км һәм көнбатыш чиге буйлап төньякка таба 250 м бара, шуннан соң, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, көнбатышка таба 6,1 км 58, 57, 56, 55, 54 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап Зирекле, Зур Полянка авыл җирлекләре һәм Әлки муниципаль районы чикләре тоташкан урында Александровка авылыннан 3,7 км көньякта 61 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш почмагында урнашкан 41 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Зирекле авыл җирлеге чиге Урманасты Шонталысы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 40 нчы тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 1,9 км «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Зур Полянка участок урманчылыгындагы 66 нчы урман кварталының төньяк һәм көнчыгыш чикләре буйлап бара, аннары, ике мәртәбә кибеп баручы инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 100 м төньяк-көнчыгышка таба уза, көньяк-көнчыгышка таба 150 м 60 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 650 м, 150 м 60 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м уза, 200 м урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак массивы буйлап, сынык сызык ясап, ике мәртәбә Кече Чирмешән елгасының кибеп баручы ермагын кисеп үтеп, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, көнчыгышка таба 50 м шушы массив буйлап, 100 м агач-куак массивының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 40 м көнчыгышка

таба һәм, яр буе агач-куак массивын кисеп үтеп, 30 м төньякка таба Кече Чирмешән елгасының кибеп баручы култыгына кадәр бара, Кече Чирмешән елгасының кибеп баручы ермагына кадәр уза, Кече Чирмешән елгасының кибеп баручы ермагы буйлап елга агымы буенча аска таба 550 м Кече Чирмешән елгасының төп үзәненә кадәр, Зирекле, Урманасты Шонталысы һәм Биләр авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Приозерная авылыннан 700 м төньякта Кече Чирмешән елгасында урнашкан 39 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Зирекле авыл җирлеге чиге Биләр авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Зирекле, Биләр авыл җирлекләре һәм Нурлат муниципаль районы чикләре тоташкан урында Гоголиха авылыннан 6,5 км көньяк-көнчыгышта «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Биләр участок урманчылыгындагы 65 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш почмагында урнашкан 43 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 2,9 км 65 нче, 64 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап бара, 150 м 76 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 1,7 км 84 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары төньякка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасы буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 900 м, урман массивы буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м һәм төньяк-көнбатышка таба 300 м уза, аннары, сынык сызык ясап, 700 м урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 750 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, Биләр – Зирекле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм Кече Чирмешән елгасының текә сул ярын кисеп үтеп, 2,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 39 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Зирекле авыл җирлеге чиге Нурлат муниципаль районы белән чиктәш җирдә 43 нче тоташу ноктасыннан алып Алексеевск муниципаль районы чиге буйлап Зирекле авыл җирлеге, Нурлат һәм Әлки муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Мораса авылыннан 1,6 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 42 нче (30 нчы) тоташу ноктасына кадәр бара.

Зирекле авыл җирлеге чиге Әлки муниципаль районы белән чиктәш җирдә 42 нче (30 нчы) тоташу ноктасыннан алып Алексеевск муниципаль районы чиге буйлап 41 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Алексеевск муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
10 нчы кушымта

**Алексеевск муниципаль районының «Кыркүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Кыркүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Кыркүл авыл җирлеге Көрнәле, Сахаровка, Урта Тигәнәле авыл җирлекләре, «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш.

Кыркүл авыл җирлеге чиге «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Кыркүл авыл җирлеге, «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге һәм Сахаровка авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Кыркүл авылыннан 2,9 км төньякта урнашкан 11 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 300 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 16 нчы урман кварталының көньяк һәм көнбатыш чикләре буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 30 м, инешне һәм Алексеевск – Биләр автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 1,2 км, 350 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 1,8 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 750 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 104 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап бара, кибеп баручы инешнең текә уң ярын кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап шушы инешкә кадәр уза, шушы инеш агымы буенча аска таба 750 м аның Курлянка кибеп баручы инешенә койган җиренә кадәр бара, аннары шушы инеш агымы буенча өскә

таба 850 м уза, шуннан соң, Курлянка инешенең текә уң ярын кисеп үтеп, көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап урман полосасына кадәр бара, 400 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м урман полосасының көньяк чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман полосаларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м һәм көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,5 км, 350 м 104 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап Кыркүл авыл җирлеге, «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге һәм Көрнәле авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Яңа Спас авылыннан 2,6 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 12 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Кыркүл авыл җирлеге чиге Сахаровка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 11 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 2,5 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр бара, шуннан соң 1,0 км инеш агымы буенча аска таба Кыркүл, Сахаровка һәм Урта Тигәнәле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кыркүл авылыннан 3,6 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 27 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кыркүл авыл җирлеге чиге Урта Тигәнәле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 27 нче тоташу ноктасыннан алып инеш агымы буенча өскә таба 3,9 км плотинага кадәр бара, шушы плотинаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 70 м төньяк-көнбатышка таба һәм көнбатыш чиге буйлап 25 м көньяк-көнчыгышка таба буаның сул ярына кадәр уза, шуннан соң 350 м көньяк-көнбатышка таба буаның сул яры буйлап бара, аннары 1,6 км инеш агымы буенча өскә таба башка буаның плотинасына кадәр уза, буаның плотинасын кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 500 м буа буйлап бара, шуннан соң 1,0 км кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба уза, аннары, Алексеевск – Биләр автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, сынык сызык ясап, көнбатышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, Кыркүл – Масловка – Ромодан автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 2,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көньякка таба 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Кыркүл, Урта Тигәнәле һәм Көрнәле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Коры Көрнәле авылыннан 2,5 км төньяк-көнчыгышта «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы

40 нчы урман кварталының көнчыгыш почмагында урнашкан 26 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Кыркүл авыл җирлеге чиге Көрнәле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 26 нчы тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 200 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 38 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 38 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, көньяк-көнбатышка таба 250 м 38 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, көньякка таба 250 м 38 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 100 м һәм төньяк-көнбатышка таба 700 м, сынык сызык ясап, төньякка таба 100 м 37 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 700 м 37 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, көнбатышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 37 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 12 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Алексеевск муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
11 нче кушымта

### Алексеевск муниципаль районының «Көрнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Көрнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Та-

тарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Көрнәле авыл җирлеге Зур Тигәнәле, Кыркүл, Лебедино, Левашево, Ромодан, Урта Тигәнәле авыл җирлекләре һәм «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш.

Көрнәле авыл җирлеге чиге «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Көрнәле авыл җирлеге, «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге һәм Кыркүл авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Яңа Спас авылыннан 2,6 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 12 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 650 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 37 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап Көрнәле авыл җирлеге, «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге һәм Лебедино авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Яңа Спас авылыннан 2,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 45 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Көрнәле авыл җирлеге чиге Кыркүл авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Көрнәле, Кыркүл һәм Урта Тигәнәле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Коры Көрнәле авылыннан 2,5 км төньяк-көнчыгышта «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 40 нчы урман кварталының көнчыгыш почмагында урнашкан 26 нчы тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 200 м 38 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 38 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, көньяк-көнбатышка таба 250 м 38 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, көньякка таба 250 м 38 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 100 м һәм төньяк-көнбатышка таба 700 м, сынык сызык ясап, төньякка таба 100 м 37 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 700 м 37 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, көнбатышка таба 300 м авыл

хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 37 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 12 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Көрнәле авыл җирлеге чиге Урта Тигәнәле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 26 нчы тоташу ноктасыннан алып көньякка таба 500 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 40 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, Кыркүл – Масловка – Ромодан автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 150 м, төньяк-көнчыгышка таба 100 уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 101 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м төньяк-көнчыгышка таба, төньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 1,4 км, көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 200 м бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м 101 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Көрнәле, Урта Тигәнәле һәм Зур Тигәнәле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Коры Көрнәле авылыннан 1,3 км көнчыгышта урнашкан 25 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Көрнәле авыл җирлеге чиге Зур Тигәнәле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Көрнәле, Зур Тигәнәле һәм Ромодан авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Масловка авылыннан 2,0 км көнчыгышта урнашкан 22 нче тоташу ноктасыннан алып көнчыгышка таба 1,1 км «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 79 нчы, 80 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап уза, шуннан соң 77 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап төньякка таба 600 м һәм төньяк чиге буйлап көнчыгышка таба 1,1 км уза, аннары, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 750 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Зур Полянка участок урманчылыгындагы 6 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 75 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң, урман массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м төньяк-көнбатышка таба, яңадан шушы урман массивын кисеп үтеп, 150 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары төньякка таба 100 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Зур Полянка участок урманчылыгындагы 6 нчы урман кварталы буйлап Каратун кибеп баручы инешенә кадәр уза, шушы инеш агымы

буенча аска таба 2,2 км буага кадәр, төньяк-көнчыгышка таба 1,0 км буа буйлап бара, аннары 1,6 км Каратун кибеп баручы инеше агымы буенча аска таба уза, шуннан соң, шушы инешнең текә уң ярын кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 25 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Көрнәле авыл җирлеге чиге Ромодан авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 22 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба 150 м, төньяк-көнбатышка таба 50 м, агач-куак массивы буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м, агач-куак массивы буйлап 100 м, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 1,3 км, көнбатышка таба 1,1 км бара, 750 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 71 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 150 м көньякка таба, көнбатышка таба 750 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Кыркүл – Масловка – Ромодан автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр уза, төньяк-көнбатышка таба 350 м шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап Көрнәле, Ромодан һәм Левашево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Масловка авылыннан 1,5 км төньяк-көнбатышта урнашкан 21 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Көрнәле авыл җирлеге чиге Левашево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 21 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 750 м Кыркүл – Масловка – Ромодан автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап «Кыркүл – Масловка – Ромодан» – Левашево автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр бара, аны кисеп үтә һәм 5,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Көрнәле, Левашево һәм Лебедино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Спас авылыннан 2,8 км көньяк-көнбатышта урнашкан 14 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Көрнәле авыл җирлеге чиге Лебедино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 14 нче тоташу ноктасыннан алып көнчыгышка таба 2,0 км урман полосасының көньяк чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап чокырга кадәр уза, 50 м чокырның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап инешкә кадәр бара, 350 м шушы инеш агымы буенча аска таба башка инеш белән кушылган җиргә кадәр уза, 3,3 км инеш агымы буенча аска таба аның Көрнәле елгасына койган җиренә кадәр бара, шуннан соң 900 м шушы елга агымы буенча өскә таба уза, аннары төньякка таба 300 м авыл хуҗалыгы

җирләре буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 250 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 37 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 45 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Алексеевск муниципаль районы»<br>муниципаль берәмлегенең һәм аның<br>составындагы муниципаль берәмлекләрнең<br>территорияләре чикләрен билгеләү<br>һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>12 нче кушымта

**Алексеевск муниципаль районының «Лебедино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Лебедино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Лебедино авыл җирлеге Бутлеровка, Войкино, Левашево, Көрнәле авыл җирлекләре, «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге һәм Лаеш муниципаль районы белән чиктәш.

Лебедино авыл җирлеге чиге «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Лебедино авыл җирлеге, «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге һәм Көрнәле авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Яңа Спас авылыннан 2,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 45 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 350 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 112 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 850 м 112 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш һәм төньяк чикләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, ике мәртәбә чокырларны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,2 км төньяк-көнбатышка таба, 900 м төньяк-көнчыгышка таба, сынык

сызык ясап, берничә мәртәбә чокырларны кисеп үтеп, 1,7 км төньяк-көнбатышка таба 112 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенә кадәр уза, 350 м аның төньяк-көнчыгыш һәм төньяк чикләре буйлап бара, көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 112 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап уза, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 112 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап бара, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 25 м 112 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап Лебедино авыл җирлеге, «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге һәм Бутлеровка авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Яңа Спас авылыннан 650 м төньякта урнашкан 13 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап урман полосасына кадәр, 950 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 67 нче урман кварталына кадәр уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 1,3 км 67 нче, 68 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 68 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м 68 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м көньяк-көнбатышка таба һәм 200 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 250 м 68 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап инешкә кадәр бара, 150 м аның агымы буенча аска таба буага кадәр уза, көньяк-көнбатышка таба 200 м буа буйлап бара, шуннан соң, «Алексеевск – Югары Колок» – Ромодан – Савинский автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 3,9 км Шкимерка елгасы агымы буенча аска таба аның Ромоданка елгасына койган җиренә кадәр уза, 4,7 км Ромоданка елгасы агымы буенча өскә таба аңа инеш койган җиргә кадәр бара, шуннан соң 1,7 км шушы инеш агымы буенча өскә таба аңа кибеп баручы инеш койган җиргә кадәр уза, 900 м аның агымы буенча өскә таба Ромодан һәм Каргалы авылларын тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр бара, 900 м көньяк-көнбатышка таба шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап Ромодан, Ялкын авыл җирлекләре һәм Әлки муниципаль районы чикләре тоташкан урында Ромодан авылыннан 4,1 км көньяк-көнбатышта урнашкан 19 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Ромодан авыл җирлеге чиге Әлки муниципаль районы белән чиктәш җирдә 19 нчы тоташу ноктасыннан алып Алексеевск муниципаль районы чиге буйлап 23 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Алексеевск муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
19 нчы кушымта

**Алексеевск муниципаль районының «Сахаровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Сахаровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Сахаровка авыл җирлеге Кыркүл, Лебяжье, Урта Тигәнәле, Кыр Шонталысы авыл җирлекләре, «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Балык Бистәсе һәм Чистай муниципаль районнары белән чиктәш.

Сахаровка авыл җирлеге чиге Балык Бистәсе муниципаль районы белән чиктәш җирдә Сахаровка, Лебяжье авыл җирлекләре һәм Балык Бистәсе муниципаль районы чикләре тоташкан урында Сакон авылыннан 3,5 км төньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 433993,78, Y = 1373320,21 координаталы 7 нче тоташу ноктасыннан алып Алексеевск муниципаль районы чиге буйлап Сахаровка авыл җирлеге, Балык Бистәсе һәм Чистай муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Речной авылыннан 4,7 км төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 8 нче (58 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Сахаровка авыл җирлеге чиге Чистай муниципаль районы белән чиктәш җирдә 8 нче (58 нче) тоташу ноктасыннан алып Алексеевск муниципаль районы чиге буйлап Сахаровка, Кыр Шонталысы авыл җирлекләре һәм Чистай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Сахаровка авылыннан 1,1 км төньякта Шентала елгасында урнашкан 9 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Сахаровка авыл җирлеге чиге Кыр Шонталысы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 9 нчы тоташу ноктасыннан алып Шентала елгасы агымы буенча өскә таба 2,7 км Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр

бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 100 м шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,0 км төньяк-көнчыгышка таба, 600 м көнчыгышка таба, 900 м көньяк-көнбатышка таба Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр бара, шуннан соң 300 м шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аны кисеп үтә һәм, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 700 м көньяк-көнбатышка таба, 300 м төньяк-көнбатышка таба һәм 600 м төньякка таба Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр бара, төньяк-көнбатышка таба 100 м шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап Шентала елгасына кадәр уза, 1,8 км аның агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары, күлне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 700 м көньяк-көнбатышка таба, Сахаровка – Зур Тигәнәле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм буаның текә уң ярын кисеп үтеп, 1,4 км төньяк-көнбатышка таба буага кадәр бара, көньяк-көнбатышка таба 450 м буа буйлап уза, шуннан соң 2,7 км Суходол инеше агымы буенча өскә таба аңа инеш койган җиргә кадәр бара, 600 м шушы инеш агымы буенча өскә таба буага кадәр уза, көньякка таба 100 м буаның уң яры буйлап бара, аннары 1,3 км инеш агымы буенча өскә таба буага кадәр уза, 1,3 км көньяк-көнбатышка таба буа буйлап бара, 2,7 км инеш агымы буенча өскә таба буага кадәр уза, көньяк-көнчыгышка таба 150 м буа буйлап бара, 1,8 км инеш агымы буенча өскә таба Сахаровка, Кыр Шонталысы һәм Урта Тигәнәле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кече Кызылъяр авылыннан 3,3 км төньяк-көнбатышта урнашкан 28 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Сахаровка авыл җирлеге чиге Урта Тигәнәле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 28 нче тоташу ноктасыннан алып инеш агымы буенча өскә таба 1,2 км буага кадәр бара, көньякка таба 1,8 км буа буйлап уза, шуннан соң 2,0 км инеш агымы буенча өскә таба Сахаровка, Урта Тигәнәле һәм Кыркүл авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кыркүл авылыннан 3,6 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 27 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Сахаровка авыл җирлеге чиге Кыркүл авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Сахаровка, Кыркүл авыл җирлекләре һәм «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Кыркүл авылыннан 2,9 км төньякта

урнашкан 11 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 2,5 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр бара, шуннан соң 1,0 км инеш агымы буенча аска таба 27 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Сахаровка авыл җирлеге чиге «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Сахаровка авыл җирлеге, «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге һәм Лебяжье авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Кече Кызылъяр авылыннан 4,8 км төньяк-көнбатышта урнашкан 10 нчы тоташу ноктасыннан алып Суходол кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба 6,2 км бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 40 м урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, төньякка таба 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 300 м «Алексеевск урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 16 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Сахаровка авыл җирлеге чиге Лебяжье авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 7 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 4,2 км Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап аның ярына кадәр бара, аннары, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 250 м сәнәгать объектының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр уза, 2,5 км шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап янәшәдәге профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чигенә кадәр бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 1,5 км янәшәдәге профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,9 км көньяк-көнчыгышка таба, 1,2 км көньяк-көнбатышка таба, 30 м көньяк-көнчыгышка таба урман полосасына кадәр бара, шуннан соң 550 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м көньяк-көнчыгышка таба, Казан — Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 3,1 км көньяк-көнбатышка таба уза, 1,4 км көньяк-көнчыгышка таба Суходол кибеп баручы инешенә кадәр бара, 400 м шушы инеш агымы буенча өскә таба буага кадәр бара, көньяк-көнбатышка таба 900 м буа буйлап, 2,1 км Суходол инеше агымы буенча өскә таба 10 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

«Алексеевск муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
20 нче кушымта

**Алексеевск муниципаль районының «Урта Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Урта Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Урта Тигәнәле авыл җирлеге Зур Тигәнәле, Кыркүл, Көрнәле, Родники, Сахаровка, Кыр Шонталысы авыл җирлекләре һәм Чистай муниципаль районы белән чиктәш.

Урта Тигәнәле авыл җирлеге чиге Сахаровка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Урта Тигәнәле, Сахаровка һәм Кыр Шонталысы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кече Кызылъяр авылыннан 3,3 км төньяк-көнбатышта урнашкан 28 нче тоташу ноктасыннан алып инеш агымы буенча өскә таба 1,2 км буага кадәр бара, көньякка таба 1,8 км буа буйлап уза, шуннан соң 2,0 км инеш агымы буенча өскә таба Урта Тигәнәле, Сахаровка һәм Кыркүл авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кыркүл авылыннан 3,6 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 27 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Урта Тигәнәле авыл җирлеге чиге Кыр Шонталысы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 28 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, текә ярларны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 900 м урман полосасы буйлап, Сахаровка – Зур Тигәнәле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 3,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап буага кадәр бара, буа плотинасын кисеп үтә һәм 500 м Тигәнәле елгасы агымы буенча аска таба аның Шентала елгасына койган җиренә кадәр уза, 2,4 км шушы елга агымы буенча өскә таба Урта Тигәнәле, Кыр Шонталысы авыл җирлекләре һәм Чистай муниципаль районы чикләре тоташкан

урында Түбән Тигәнәле авылыннан 1,7 км көнчыгышта Шентала елгасында урнашкан 29 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Урта Тигәнәле авыл җирлеге чиге Чистай муниципаль районы белән чиктәш җирдә 29 нчы тоташу ноктасыннан алып Алексеевск муниципаль районы чиге буйлап Урта Тигәнәле, Родники авыл җирлекләре һәм Чистай муниципаль районы авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Түбән Тигәнәле авылыннан 2,0 км көнчыгышта Шентала елгасында урнашкан 30 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Урта Тигәнәле авыл җирлеге чиге Родники авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Урта Тигәнәле, Родники һәм Зур Тигәнәле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Родники авылыннан 1,8 км көньяк-көнбатышта урнашкан 32 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м төньяк-көнбатышка таба һәм 150 м төньяк-көнчыгышка таба, 50 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Зур Полянка участок урманчылыгындагы 103 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң төньякка таба 1,1 км урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, «Сахаровка – Зур Тигәнәле» – Родники автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, төньяк-көнчыгышка таба 150 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м төньяк-көнчыгышка таба, 1,6 км төньяк-көнбатышка таба, 50 м төньяк-көнчыгышка таба урман полосасына кадәр уза, 250 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,4 км төньяк-көнчыгышка таба һәм, Тигәнәле елгасының текә уң ярын кисеп үтеп, 400 м төньяк-көнбатышка таба Тигәнәле елгасына кадәр уза, аның агымы буенча аска таба 400 м бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 3,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Булачка елгасына кадәр уза, 2,8 км шушы елга агымы буенча аска таба аның Шентала елгасына койган җиргә кадәр, 30 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Урта Тигәнәле авыл җирлеге чиге Зур Тигәнәле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Урта Тигәнәле, Зур Тигәнәле һәм Көрнәле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Коры Көрнәле авылыннан 1,3 км көнчыгышта урнашкан 25 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, чокырны кисеп

үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, 1,6 км шушы инеш агымы буенча өскә таба уза, аннары, кибеп баручы инешнең текә уң ярын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м төньяк-көнчыгышка таба, чокырны кисеп үтеп, 450 м көньяк-көнчыгышка таба урман полосасына кадәр бара, 950 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, төньяк-көнчыгышка таба 1,1 км бара, аннары көнчыгышка таба 650 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, Алексеевск – Биләр автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң, кибеп баручы инешне һәм Сахаровка – Зур Тигәнәле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 2,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 50 м плотинаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, Тигәнәле елгасын һәм аның текә ярларын кисеп үтеп, 3,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Зур Полянка участок урманчылыгындагы 92 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш почмагына кадәр бара, көнчыгышка таба 200 м шушы урман кварталының төньяк чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 32 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Урта Тигәнәле авыл җирлеге чиге Көрнәле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Урта Тигәнәле, Көрнәле һәм Кыркүл авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Коры Көрнәле авылыннан 2,5 км төньяк-көнчыгышта «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 40 нчы урман кварталының көнчыгыш почмагында урнашкан 26 нчы тоташу ноктасыннан алып көньякка таба 500 м 40 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, Кыркүл – Масловка – Ромодан автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 150 м, төньяк-көнчыгышка таба 100 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 101 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 200 м, төньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 1,4 км, көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 200 м бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м 101 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 25 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Урта Тигәнәле авыл җирлеге чиге Кыркүл авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 27 нче тоташу ноктасыннан алып инеш агымы буенча өскә таба 3,9 км плотинага кадәр бара, шушы плотинаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 70 м төньяк-көнбатышка таба һәм көнбатыш чиге буйлап 25 м көньяк-көнчыгышка таба буаның сул ярына кадәр уза, шуннан соң 350 м көньяк-көнбатышка таба буаның сул яры буйлап бара, аннары 1,6 км инеш агымы буенча өскә таба башка буаның плотинасына кадәр уза, буаның плотинасын кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 500 м буа буйлап бара, шуннан соң 1,0 км кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба уза, аннары, Алексеевск – Биләр автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, сынык сызык ясап, көнбатышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, Кыркүл – Масловка – Ромодан автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 2,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көньякка таба 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 26 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Алексеевск муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
21 нче кушымта

## Алексеевск муниципаль районының «Кыр Шонталысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Кыр Шонталысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Кыр Шонталысы авыл җирлеге Сахаровка, Урта Тигәнәле авыл җирлекләре һәм Чистай муниципаль районы белән чиктәш.

Кыр Шонталысы авыл җирлеге чиге Чистай муниципаль районы белән чиктәш җирдә Кыр Шонталысы, Сахаровка авыл

җирлекләре һәм Чистай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Сахаровка авылыннан 1,1 км төньякта Шентала елгасында урнашкан 9 нчы тоташу ноктасыннан алып Алексеевск муниципаль районы чиге буйлап Кыр Шонталысы, Урта Тигәнәле авыл җирлекләре һәм Чистай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Түбән Тигәнәле авылыннан 1,7 км көнчыгышта Шентала елгасында урнашкан 29 нчы тоташу ноктасына кадәруза.

Кыр Шонталысы авыл җирлеге чиге Урта Тигәнәле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Кыр Шонталысы, Урта Тигәнәле һәм Сахаровка һәм авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кече Кызылъяр авылыннан 3,3 км төньяк-көнбатышта урнашкан 28 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, чокырны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 900 м урман полосасы буйлап, Сахаровка – Зур Тигәнәле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 3,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап буага кадәр бара, буа плотинасын кисеп үтә һәм 500 м Тигәнәле елгасы агымы буенча аска таба аның Шентала елгасына койган җиренә кадәр уза, 2,4 км шушы елга агымы буенча өскә таба 29 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Кыр Шонталысы авыл җирлеге чиге Сахаровка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 9 нчы тоташу ноктасыннан алып Шентала елгасы агымы буенча өскә таба 2,7 км Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 100 м шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,0 км төньяк-көнчыгышка таба, 600 м көнчыгышка таба, 900 м көньяк-көнбатышка таба Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр бара, шуннан соң 300 м шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аны кисеп үтә һәм, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 700 м көньяк-көнбатышка таба, 300 м төньяк-көнбатышка таба һәм 600 м төньякка таба Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр бара, төньяк-көнбатышка таба 100 м шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап Шентала елгасына кадәр уза, 1,8 км аның агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары, күлне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап

700 м көньяк-көнбатышка таба, Сахаровка – Зур Тигәнәле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм буаның текә уң ярын кисеп үтеп, 1,4 км төньяк-көнбатышка таба буага кадәр бара, көньяк-көнбатышка таба 450 м буа буйлап уза, шуннан соң 2,7 км Суходол инеше агымы буенча өскә таба аңа инеш койган җиргә кадәр бара, 600 м шушы инеш агымы буенча өскә таба буага кадәр уза, көньякка таба 100 м буаның уң яры буйлап бара, аннары 1,3 км инеш агымы буенча өскә таба буага кадәр уза, 1,3 км көньяк-көнбатышка таба буа буйлап бара, 2,7 км инеш агымы буенча өскә таба буага кадәр уза, көньяк-көнчыгышка таба 150 м буа буйлап бара, 1,8 км инеш агымы буенча өскә таба 28 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Алексеевск муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
22 нче кушымта

**Алексеевск муниципаль районының «Ялкын авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Ялкын авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Ялкын авыл җирлеге Войкино, Левашево, Ромодан авыл җирлекләре, Әлки һәм Спас муниципаль районнары белән чиктәш.

Ялкын авыл җирлеге чиге Войкино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Ялкын, Войкино һәм Левашево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Левашево авылыннан 3,2 км көньяк-көнбатышта урнашкан 16 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,5 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 56 нчы урман кварталына кадәр уза, аннары, сынык сызык ясап, көньякка

таба 2,2 км 56 нчы, 57 нче урман кварталлары буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Актай елгасын кисеп үтеп, 50 м комлык буйлап, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 1,3 км урман полосасы буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,0 км урман полосасы буйлап, 400 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Ялкын, Войкино авыл җирлекләре һәм Спас муниципаль районы чикләре тоташкан урында Войкино авылыннан 4,7 км көньякта урнашкан 17 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Ялкын авыл җирлеге чиге Спас муниципаль районы белән чиктәш җирдә 17 нче тоташу ноктасыннан алып Алексеевск муниципаль районы чиге буйлап Ялкын авыл җирлеге, Спас һәм Әлки муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Караваево авылыннан 4,8 км көньяк-көнбатышта урнашкан 18 нче (31 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Ялкын авыл җирлеге чиге Әлки муниципаль районы белән чиктәш җирдә 18 нче (31 нче) тоташу ноктасыннан алып Алексеевск муниципаль районы чиге буйлап Ялкын, Ромодан авыл җирлекләре һәм Әлки муниципаль районы чикләре тоташкан урында Ромодан авылыннан 4,1 км көнбатышта урнашкан 19 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Ялкын авыл җирлеге чиге Ромодан авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Ялкын, Ромодан һәм Левашево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Левашево авылыннан 1,6 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 20 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап урман полосасына кадәр, 950 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 67 нче урман кварталына кадәр уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 1,3 км 67 нче, 68 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 68 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м 68 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м көньяк-көнбатышка таба һәм 200 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары, сынык сызык ясап,

көньяк-көнбатышка таба 250 м 68 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап инешкә кадәр бара, 150 м аның агымы буенча аска таба буага кадәр уза, көньяк-көнбатышка таба 200 м буа буйлап бара, шуннан соң, «Алексеевск – Югары Колок» – Ромодан – Савинский автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 3,9 км Шкимерка елгасы агымы буенча аска таба аның Ромоданка елгасына койган җиренә кадәр уза, 4,7 км Ромоданка елгасы агымы буенча өскә таба аңа инеш койган җиргә кадәр бара, шуннан соң 1,7 км шушы инеш агымы буенча өскә таба аңа кибеп баручы инеш койган җиргә кадәр уза, 900 м аның агымы буенча өскә таба Ромодан һәм Каргалы авылларын тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр бара, 900 м көньяк-көнбатышка таба шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап 19 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Ялкын авыл җирлеге чиге Левашево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 20 нче тоташу ноктасыннан алып кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба 300 м бара, аннары көнбатышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 400 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Алексеевск участок урманчылыгындагы 64 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 150 м, төньякка таба 350 м, Алексеевск – Югары Колок автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көнбатышка таба 1,8 км, төньяк-көнбатышка таба 850 м урман полосасына кадәр уза, көнбатышка таба 2,0 км урман полосасының көньяк чиге буйлап 16 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.».

## 1383. «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (II өлеш); 2008, № 12 (IX өлеш) әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 30 декабре
№ 148-ТРЗ

«Түбән Кама муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
үзгәрешләр кертү хакында»
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

**«Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кертелә торган үзгәрешләр**

2 – 19 кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Түбән Кама муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

**«Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Түбән Кама муниципаль районы Мамадыш, Алабуга, Тукай, Чистай, Яңа Чишмә һәм Зәй муниципаль районнары белән чиктәш.

«Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Түбән Кама, Мамадыш һәм Чистай муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Ачы авылыннан

6,3 км төньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 1 нче (60 нчы) тоташу ноктасыннан алып көнчыгышка таба 50 м агач-куак массивының көньяк чиге буйлап, култыкны кисеп үтеп, 150 м агач-куак массивы буйлап, 100 м сазлык буенча, 350 м агач-куак массивы буйлап уза, саклаучы дамба буйлап 150 м бара, аны кисеп үтә, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 350 м сазлыкның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, күлне кисеп үтеп, 550 м, сазлык буйлап 250 м бара, аннары 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м сазлыкның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 400 м күл буенча, 150 м сазлыкның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сазлыкны кисеп үтеп, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Зур Костыль күле буйлап 40 м уза, шуннан соң 150 м агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 30 м күлне кисеп үтеп, 350 м сазлык буенча, сынык сызык ясап, 50 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 100 м көньяк-көнчыгышка таба агач-куак массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, сынык сызык ясап, 600 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, төньяк-көнчыгышка таба агач-куак массивы буйлап 200 м һәм әлеге массивның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, саклаучы дамбаны кисеп үтеп, 100 м, агач-куак массивы буйлап 100 м бара, сынык сызык ясап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м агач-куак массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м сазлык буенча, 500 м Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча, урман массивын кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м күл буйлап бара, аннары 100 м көнчыгышка таба, саклаучы дамбаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң күл буйлап 300 м көнчыгышка таба һәм, дамбаны кисеп үтеп, 100 м төньяк-көнчыгышка таба, 30 м агач-куак массивы буйлап бара, аннары Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 650 м төньяк-көнчыгышка таба, 6,0 км көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 10,2 км төньяк-көнчыгышка таба, 150 м көньяк-көнчыгышка таба Куйбышев сусаклагычы ярына кадәр уза, шуннан соң көньякка таба 100 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 150 м күл буенча, 50 м күлнең көнбатыш яры буйлап, 50 м агач-куак массивы буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, каналны кисеп үтеп, 150 м бара, аннары инеш агымы буйлап 50 м аска таба, Гнилуха күле буйлап 650 м уза, әлеге күл буйлап 20 м көнчыгышка таба, инеш агымы буйлап 450 м өскә

таба бара, шуннан соң 50 м төньяк-көнчыгышка таба канал буйлап уза, аны кисеп үтеп, инеш агымы буенча, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м аска таба, төньяк-көнчыгышка, сынык сызык ясап, 1,1 км Становое күле буенча, агач-куак массивын кисеп үтеп, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м сазлык буенча, көнчыгышка таба, күлне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 100 м, сазлыкның көньяк чиге буйлап 150 м бара, аннары 100 м көньяк-көнчыгышка таба һәм, сынык сызык ясап, 2,1 км көньякка таба Каракүл күле буйлап уза, төньяк-көнчыгышка таба инеш агымы буйлап 1,0 км аска таба, сынык сызык ясап, 150 м күл буенча, инеш агымы буйлап 200 м аска таба, сынык сызык ясап, 600 м күл буенча, инеш агымы буйлап 1,4 км аска таба, сынык сызык ясап, 200 м күл буенча, инеш агымы буйлап 30 м аска таба Прось елгасына кадәр бара, шуннан соң 40 м көньяк-көнчыгышка таба әлеге елга буенча, аның агымы буйлап 6,4 км өскә таба һәм 70 м төньяк-көнбатышка таба Грязца инеше тамагына кадәр уза, аннары әлеге инеш агымы буйлап 3,7 км өскә таба дәвам итә, аннары 40 м көнчыгышка таба сазлык буенча, 250 м төньяк-көнчыгышка таба сазлыкның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм Куйбышев сусаклагычының текә ярын кисеп үтеп, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, әлеге сусаклагыч акваториясе буйлап 500 м төньякка таба Түбән Кама, Мамадыш һәм Алабуга муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Березовая Грива авылыннан 4,0 км төньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 16 нчы (61 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 16 нчы (61 нче) тоташу ноктасыннан алып Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 550 м көнчыгышка таба, 150 м исемсез утрауны кисеп үтеп, 350 м төньяк-көнчыгышка таба, Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 50 м, 250 м исемсез утрауны кисеп үтеп уза, кабат Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 1,7 км дәвам итә, алга таба Иске Кама кушылдыгы агымы буйлап 11,5 км өскә таба бара, аннары Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 5,5 км төньяк-көнчыгышка таба һәм 450 м көньяк-көнчыгышка таба уза, алга таба күмәк бакчалар буйлап 1,6 км бара, күлне кисеп үтеп, 100 м, профильле автомобиль юлы буйлап 250 м төньяк-көнчыгышка таба уза, аннары күмәк бакчалар буйлап 750 м төньяк-көнчыгышка таба, 800 м төньякка таба бара, шуннан соң кабат, сынык сызык ясап, 2,1 км төньяк-көнчыгышка таба уза, аннары 550 м көньяк-көнчыгышка таба Соболеково күле буйлап бара, шуннан

соң 500 м төньяк-көнчыгышка таба кабат күмәк бакчалар буйлап уза, алга таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 500 м һәм 3,4 км көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 1,9 км көнчыгышка таба, 350 м төньяк-көнбатышка таба бара, аннары, сынык сызык ясап, 700 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,2 км төньяк-көнбатышка таба күл буенча, 100 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, күлне кисеп үтеп, 50 м кибеп баручы инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м уза, шуннан соң 200 м агач-куак массивы буйлап, 50 м төньяк-көнчыгышка таба Криуша елгасы буйлап һәм аның агымы буйлап 2,0 км өскә таба бара, аннары Криуша елгасы буйлап 60 м көньяк-көнбатышка таба аның сул ярына кадәр уза, шуннан соң 650 м агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 350 м көньяк-көнбатышка таба, 2,1 км көнчыгышка таба, 9,3 км төньяк-көнчыгышка таба Түбән Кама, Алабуга һәм Тукай муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Прости авылынннан 8,3 км төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 20 нче (62 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 1 нче (60 нчы) тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, тар утрауларны кисеп үтеп, 1,5 км көньяк-көнбатышка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап уза, алга таба «Зәй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кошнәк участок урманчылыгындагы 91 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 300 м көнбатышка таба һәм төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,1 км көньяк-көнбатышка таба бара, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м сазлык буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 100 м сазлыкның көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м сазлыкның төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Чистай участок урманчылыгындагы 95 нче урман кварталы аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, Просто елгасы буйлап 30 м төньяк-көнбатышка таба һәм 2,9 км аның агымы буйлап өскә таба уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 30 м Прость елгасы буйлап аның уң ярына кадәр, 200 м сазлык буенча, 200 м 94 нче урман кварталындагы аерымланган кишәрлекнең көнбатыш чиге буйлап, 150 м сазлык буенча, 100 м урман массивы буйлап бара,

аннары, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 3,4 км күл буенча, агач-куак массивын кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба, утрауларны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 1,9 км Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча, 1,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 850 м Чишмә Тамагы култыгы буйлап һәм, Чистай – Түбән Кама автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 850 м көньяк-көнбатышка таба уза, 150 м агач-куак массивы буйлап, 150 м агач-куак массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, утрауларны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,9 км Чишмә Тамагы култыгы буенча, 500 м агач-куак массивы буйлап уза, аннары көнбатышка таба 850 м Чишмә Тамагы култыгы буенча, 150 м сазлык буенча, 50 м Чишмә Тамагы култыгы буенча, «Чистай – Түбән Кама» – Карамалы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм Ташлы инешен кисеп үтеп, 2,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, 900 м урман полосасы буйлап, 1,0 км урман полосасының төньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының төньяк чиге буйлап бара, алга таба көньякка таба 550 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 900 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап уза, Талкыш елгасын һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 550 м кабат авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 750 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 3,4 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, көньякка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 950 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 100 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 2,3 км урман полосасының көньяк чиге буйлап, чокырны һәм Елшанка елгасының текә уң ярын кисеп үтеп, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап әлеге елгага кадәр бара, 6,2 км әлеге елга агымы буйлап өскә таба Түбән Кама, Чистай һәм Яңа Чишмә муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Городище авылыннан 9,5 км көньяк-көнбатышта урнашкан 10 нчы (82 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 20 нче (62 нче) тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, аннары 250 м агач-ку-

ак массивының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң агач-куак массивының көнчыгыш чиге буйлап 150 м көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, Курья күлен кисеп үтеп, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 1,6 км Олы Бережное күле буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м төньяк-көнбатышка таба, 300 м көньяк-көнбатышка таба бара, 300 м күлнең көньяк-көнчыгыш яры буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,0 км көньяк-көнчыгышка таба һәм, сынык сызык ясап, 550 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 650 м Пестянка күле буйлап, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м көньякка таба, Саракумово күленең төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш ярлары буйлап, сынык сызык ясап, 700 м көньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 700 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 850 м Prость елгасына кадәр уза, аннары әлеге елга агымы буйлап 1,0 км өскә таба, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,0 км көньякка таба, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,2 км күл буйлап көнчыгышка таба бара, агач-куак массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 600 м, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 650 м уза, аннары, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, кибеп баручы инеш агымы буйлап 550 м өскә таба, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кабат кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м көньяк-көнчыгышка таба, 450 м урман полосасы буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң 2,2 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 200 м урман массивының төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап, көньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары «Түбән Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Биклән участок урманчылыгындагы 114 нче урман кварталы аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап 1,3 км бара, 850 м агач-куак полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м агач-куак полосасы буйлап, 50 м агач-куак полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 450 м агач-куак полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м агач-куак массивы полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 20 м көньяк-көнбатышка таба һәм 30 м көньяк-көнчыгышка таба, 250 м агач-куак массивы полосасының көньяк-көнбатыш

чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м һәм көньяк-көнбатышка таба 1,3 км, сынык сызык ясап, 43 нче, 44 нче урман кварталларының төньяк һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап 1,9 км көньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң 44 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 800 м көньяк-көнбатышка таба, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 50 м 44 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, көнчыгышка таба 650 м 56 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 56 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап 100 м һәм көньяк-көнбатышка таба көнчыгыш чиге буйлап 650 м, «Чаллы—Зәй — Әлмәт» — Түбән Кама автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м уза, аннары 750 м 56 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 70 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 200 м көньяк-көнчыгышка таба, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 800 м 70 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап уза, Куйбышев тимер юлы тармагына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 3,2 км 70 нче, 82 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 4,2 км 82, 93, 92, 102 нче урман кварталларының көнчыгыш, көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап, төньяк-көнбатышка таба 1,8 км 101 нче, 100 нче урман кварталларының көньяк һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап уза, аннары, Мартышка елгасын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 100, 90, 79 нчы урман кварталларының көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап 2,1 км төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 79 нчы, 89 нчы урман кварталларының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап 1,7 км көньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 89 нчы урман кварталының көньяк һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап 600 м төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары, сынык сызык ясап, 1,1 км 88 нче, 99 нчы урман кварталларының көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап, 150 м сәнәгать объекты буйлап бара, сынык сызык ясап, 99 нчы, 107 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап 1,8 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньякка таба 550 м һәм төньяк-көнбатышка таба 200 м, буа буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 30 м, буа буйлап 200 м, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буй-

лап, сынык сызык ясап, көнбатышка таба 550 м бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 1,6 км көньякка таба «Түбән Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Биклән участок урманчылыгындагы 110 нчы урман кварталының көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап һәм «Түбән Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кызыл Юл участок урманчылыгындагы 3 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 150 м күмәк бакчалар буйлап, көньякка таба 1,2 км 3 нче, 5 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 1,5 км 14 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, көньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Алансу инешен кисеп үтеп, 200 м 14 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 14 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 14 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,3 км көньяк-көнбатышка таба бара, көньякка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 1,0 км 14 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап, 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 250 м 18 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба, 2,0 км 18 нче урман кварталының көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап Түбән Кама, Тукай һәм Зәй муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Кушай авылыннан 5,0 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 26 нчы (87 нче) тоташу ноктасына кадәр бара.

«Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 10 нчы (82 нче) тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 350 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасы буйлап, 150 м урман полосасының көньяк чиге буйлап уза, алга таба 1,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Казан – Оренбург» – Городище – Ялантау автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,4 км «Зәй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кошнәк участок урманчылыгындагы 98 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш, көньяк һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап,

Каенлы авыл җирлеге чиге Кызыл Чапчак авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 28 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м 76 нчы урман кварталындагы аерымланган кишәрлекнең төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, сазлыкны, Зәй елгасын һәм «Чистай — Түбән Кама» — Кызыл Чапчак — Югары Чаллы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 3,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Каенлы, Кызыл Чапчак һәм Майская Горка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кызыл Чапчак авылыннан 2,1 км төньяк-көнбатышта урнашкан 42 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Каенлы авыл җирлеге чиге Майская Горка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 42 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 600 м кибеп баручы инешкә кадәр уза, аның агымы буйлап аска таба 2,0 км бара, аннары, агач-куак массивын кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 350 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м Зәй — Сухарево автомобиль юлы буйлап Каенлы,

Майская Горка һәм Сухарево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Сименеево авылыннан 450 м көнчыгышта урнашкан 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Каенлы авыл җирлеге чиге Сухарево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 32 нче тоташу ноктасыннан алып 100 м төньяк-көнбатышка таба Зәй – Сухарево автомобиль юлы буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,1 км төньяк-көнбатышка таба, дамбаны һәм текә ярны кисеп үтеп, көнбатышка таба 300 м бара, шуннан соң Инеш елгасы агымы буйлап аска таба 4,2 км аңа Развила елгасы койган урынга кадәр уза, аннары әлеге елга агымы буйлап өскә таба 2,2 км бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба, Развила елгасының текә ярын, Чистай – Түбән Кама автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм чокырны кисеп үтеп, 4,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасы буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 950 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 500 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман полосаларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 500 м һәм көньяк чиге буйлап көнбатышка таба 500 м, урман полосасы буйлап 500 м уза, аннары көньякка таба 400 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньякка таба 150 м, көнбатышка таба 400 м һәм, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, урман полосасының көньяк чиге буйлап 50 м уза, аннары «Зәй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Болгар участок урманчылыгындагы 9 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 1,2 км, көньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 250 м, күмәк бакчаларның төньяк чиге буйлап 200 м, чокырны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Просъ елгасына кадәр бара, аннары шушы елга буйлап өскә таба 600 м 15 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Түбән Кама муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
8 нче кушымта

**Түбән Кама муниципаль районының «Кармалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Кармалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Кармалы авыл җирлеге Ялантау, Иске Чишмә авыл җирлекләре, Яңа Чишмә һәм Чистай муниципаль районнары белән чиктәш.

Кармалы авыл җирлеге чиге Чистай муниципаль районы белән чиктәш җирдә Кармалы авыл җирлеге, Чистай һәм Яңа Чишмә муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Городище авылыннан 9,5 км көньяк-көнбатышта урнашкан 10 нчы (82 нче) тоташу ноктасыннан алып Түбән Кама муниципаль районы чиге буйлап Кармалы, Иске Чишмә авыл җирлекләре һәм Чистай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Свердловец поселогыннан 2,3 км төньяк-көнчыгышта Чишмә елгасы акваториясендә урнашкан 8 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кармалы авыл җирлеге чиге Иске Чишмә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 8 нче тоташу ноктасыннан алып 3,6 км Чишмә елгасы агымы буйлап өскә таба уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 750 м сазлык буенча, сазлыкны кисеп үтеп, 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Кармалы, Иске Чишмә һәм Ялантау авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Чишмә авылыннан 2,8 км көньяк-көнбатышта урнашкан 9 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Кармалы авыл җирлеге чиге Ялантау авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Кармалы, Ялантау авыл җирлекләре һәм Яңа Чишмә муниципаль районы чикләре тоташкан урында Городище авылыннан 6,6 км көньяк-көнбатышта урнашкан 11 нче

тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба, урман полосасын кисеп үтеп, 2,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 950 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 100 м чокыр төбе буйлап инешкә кадәр бара, Ширәмәт – Кармалы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, аның агымы буйлап аска таба уза, шуннан соң Чишмә елгасы агымы буйлап аска таба 8,2 км бара, аннары, текә ярны кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Зәй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кошнәк участок урманчылыгындагы 69 нчы, 67 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,5 км 9 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Кармалы авыл җирлеге чиге Яңа Чишмә муниципаль районы белән чиктәш җирдә 11 нче тоташу ноктасыннан алып Түбән Кама муниципаль районы чиге буйлап 10 нчы (82 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Түбән Кама муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
9 нчы кушымта

**Түбән Кама муниципаль районының «Кызыл Чапчак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Кызыл Чапчак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Кызыл Чапчак авыл җирлеге Каенлы, Майская Горка, Түбән Уратма, Шәңгәлче авыл җирлекләре һәм Зәй муниципаль районы белән чиктәш.

Кызыл Чапчак авыл җирлеге чиге Зәй муниципаль районы белән чиктәш җирдә Кызыл Чапчак, Шәңгәлче авыл җирлекләре һәм Зәй муниципаль районы чикләре тоташкан урында Түбән Чаллы авылыннан 3,0 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасыннан алып Түбән Кама муниципаль районы чиге буйлап Кызыл Чапчак, Түбән Уратма авыл җирлекләре һәм Зәй муниципаль районы чикләре тоташкан урында Югары Чаллы авылыннан 2,2 км көньякта урнашкан 30 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Кызыл Чапчак авыл җирлеге чиге Түбән Уратма авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 30 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м «Зәй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Болгар участок урманчылыгындагы 50 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 700 м 50 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м 50 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м уза, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 50 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 100 м, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 50 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап бара, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 50 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м һәм 49 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 550 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м, 49 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 400 м һәм төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 850 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба 100 м, төньяк-көнчыгышка таба 1,6 км уза, буаны кисеп үтеп, 44 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 150 м бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 39 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, төньякка таба 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м буаның сулъяк яры буйлап, 100 м 39 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап Кызыл Чапчак, Түбән Уратма һәм Майская Горка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Олы Аты авылыннан 2,1 км көньяк-көнбатышта урнашкан 31 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кызыл Чапчак авыл җирлеге чиге Майская Горка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 31 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м буа буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 200 м, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба

2,6 км, төньяк-көнбатышка таба 550 м, агач-куак массивының көньяк чиге буйлап 150 м бара, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 100 м, сынык сызык ясап, көнчыгышка таба 200 м уза, кибеп баручы инеш агымы буйлап аска таба 350 м бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м карьер буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң карьер буйлап төньяк-көнчыгышка таба 50 м, төньяк-көнбатышка таба 600 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м төньяк-көнбатышка таба, урман полосасын кисеп үтеп, 100 м төньяк-көнбатышка таба Зәй – Сухарево автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 2,3 км, төньяк-көнбатышка таба 600 м Кызыл Чапчак, Майская Горка һәм Каенлы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кызыл Чапчак авылыннан 2,1 км төньяк-көнбатышта урнашкан 42 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кызыл Чапчак авыл җирлеге чиге Каенлы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Кызыл Чапчак, Каенлы һәм Шәңгәлче авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Үскә авылыннан 3,1 км көнчыгышта урнашкан 28 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м 76 нчы урман кварталындагы аерымланган кишәрлекнең төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, сазлыкны, Зәй елгасын, «Чистай – Түбән Кама» – Кызыл Чапчак – Югары Чаллы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 3,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 42 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Кызыл Чапчак авыл җирлеге чиге Шәңгәлче авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 28 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 2,8 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, инешләрне кисеп үтеп, 2,5 км «Түбән Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кызыл Юл участок урманчылыгындагы 60 нчы, 61 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 300 м 62 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 62 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м бара, аннары 200 м 62 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап һәм 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр уза, аның агымы буйлап өскә таба 950 м 29 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Түбән Кама муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
10 нчы кушымта

**Түбән Кама муниципаль районының
«Красный Ключ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге
территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Красный Ключ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Красный Ключ авыл җирлеге «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге, Прости авыл җирлеге һәм Алабуга муниципаль районы белән чиктәш.

Красный Ключ авыл җирлеге чиге Алабуга муниципаль районы белән чиктәш җирдә Красный Ключ авыл җирлеге, «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Алабуга муниципаль районы чикләре тоташкан урында Пробуждение поселогыннан 900 м төньяк-көнбатышта урнашкан 19 нчы тоташу ноктасыннан алып Түбән Кама муниципаль районы чиге буйлап Красный Ключ, Прости авыл җирлекләре һәм Алабуга муниципаль районы чикләре тоташкан урында Красный Ключ поселогыннан 2,7 км көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=463815,04, Y=2289998,28 координаталы 44 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Красный Ключ авыл җирлеге чиге Прости авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 44 нче тоташу ноктасыннан алып 250 м төньякка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап Красный Ключ, Прости авыл җирлекләре һәм «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Красный Ключ поселогыннан 2,7 км төньяк-көнчыгышта Комлык утравының төньяк чигендә урнашкан 43 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Красный Ключ авыл җирлеге чиге «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 19 нчы тоташу ноктасыннан алып Соболеково күле буйлап 750 м төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 2,1 км төньяк-көнбатышка таба уза, ан-

нары көньякка таба 100 м сазлык буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, «Түбән Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Биклән участок урманчылыгындагы 6 нчы урман кварталы буйлап 600 м көнчыгышка таба уза, аннары 1 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 1,0 км 1 нче урман кварталы буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 1 нче, 2 нче урман кварталлары буйлап 1,6 км көнчыгышка таба уза, аннары Түбән Кама шәһәрен Красный Ключ поселогы белән тоташтыра торган автомобиль юлы буйлап 300 м көньякка таба бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 30 м көнчыгышка таба уза, аннары 3 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 150 м көньякка таба, көньяк чиге буйлап 1,1 км көнчыгышка таба, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң 3 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 300 м төньякка таба уза, аннары Куйбышев сусаклагычының сулъяк яры буйлап 350 м төньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 850 м көнчыгышка таба, 1,4 км Комлык утравының төньяк чиге буйлап 43 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Түбән Кама муниципаль районы»<br>
муниципаль берәмлегенең һәм аның<br>
составындагы муниципаль берәмлекләрнең<br>
территорияләре чикләрен билгеләү<br>
һәм аларның статусы турында»<br>
Татарстан Республикасы Законына<br>
11 нче кушымта

## Түбән Кама муниципаль районының «Майская Горка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Майская Горка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Майская Горка авыл җирлеге Каенлы, Кызыл Чапчак, Түбән Уратма, Сухарево һәм Ширәмәт авыл җирлекләре белән чиктәш.

Майская Горка авыл җирлеге чиге Сухарево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Майская Горка, Сухарево һәм Ширәмәт авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Выгороженный Ключ авылыннан 200 м көнбатышта урнашкан 33 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 250 м агач-куак массивы буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 250 м буа буйлап уза, инеш агымы буйлап аска таба 100 м бара, көнчыгышка таба 150 м буа буйлап уза, Чистай – Түбән Кама автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, инеш агымы буйлап аска таба 700 м бара, көньяк-көнчыгышка таба 400 м буа буйлап, инеш агымы буйлап аска таба 1,6 км уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 750 м «Зәй – Сухарево» – Болгар автомобиль юлы буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 600 м, төньяк-көнчыгышка таба 100 м уза, шуннан соң, «Зәй – Сухарево» – Болгар автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, кибеп баручы инеш агымы буйлап аска таба 2,1 км уза, аннары 2,4 км шушы инеш агымы буйлап аска таба башка инеш белән кушылганчы бара, көньяк-көнчыгышка таба 1,5 км инеш агымы буйлап өскә таба уза, шуннан соң агач-куак массивларын кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Майская Горка, Сухарево һәм Каенлы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Сименеево авылыннан 450 м көнчыгышта урнашкан 32 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Майская Горка авыл җирлеге чиге Каенлы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Майская Горка, Каенлы һәм Кызыл Чапчак авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кызыл Чапчак авылыннан 2,1 км төньяк-көнбатышта урнашкан 42 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 600 м кибеп баручы инешкә кадәр уза, аның агымы буйлап аска таба 2,0 км бара, аннары, агач-куак массивын кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 350 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м Зәй – Сухарево автомобиль юлы буйлап 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Майская Горка авыл җирлеге чиге Кызыл Чапчак авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Майская Горка, Кызыл Чапчак һәм Түбән Уратма авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Олы Аты авылыннан 2,1 км көньяк-көнбатышта урнашкан 31 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл

хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м буа буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 200 м, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 2,6 км, төньяк-көнбатышка таба 550 м, агач-куак массивының көньяк чиге буйлап 150 м бара, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 100 м, сынык сызык ясап, көнчыгышка таба 200 м уза, кибеп баручы инеш агымы буйлап аска таба 350 м бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м карьер буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң карьер буйлап төньяк-көнчыгышка таба 50 м, төньяк-көнбатышка таба 600 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м төньяк-көнбатышка таба, урман полосасын кисеп үтеп, 100 м төньяк-көнбатышка таба Зәй – Сухарево автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 2,3 км, төньяк-көнбатышка таба 600 м 42 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Майская Горка авыл җирлеге чиге Түбән Уратма авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 31 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 100 м «Зәй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Болгар участок урманчылыгындагы 39 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап, инешне кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 39 нчы, 38 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш, төньяк чикләре буйлап 1,1 км уза, аннары төньякка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 38 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м һәм 38 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 100 м бара, шуннан соң көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,6 км 38, 37, 36 нчы урман кварталларының төньяк чиге буйлап уза, аннары 36 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 550 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м бара, сынык сызык ясап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 36, 41, 40 нчы урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап 3,0 км уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,2 км 40 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 45 нче, 51 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап көньякка таба 700 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 150 м, төньяк-көнбатышка таба 150 м, көньяк-көнбатышка таба 350 м, текә

ярның төньяк чиге буйлап 550 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 500 м, төньяк-көнбатышка таба 200 м уза, 102 нче урман кварталындагы аерымланган кишәрлекнең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, 102 нче урман кварталындагы аерымланган кишәрлекнең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көнбатышка таба 102 нче урман кварталындагы аерымланган кишәрлекнең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 300 м уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 102 нче урман кварталындагы аерымланган кишәрлекнең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньякка таба 50 м, төньяк-көнбатышка таба 150 м уза, шуннан соң 33 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 600 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м бара, аннары Уратма елгасы агымы буйлап аска таба 1,2 км уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 1,8 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м 32 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м 32 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, Уратма елгасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, аннары әлеге елга агымы буйлап аска таба 1,4 км Майская Горка, Түбән Уратма һәм Ширәмәт авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ширәмәт авылыннан 500 м көнчыгышта Уратма елгасында урнашкан 34 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Майская Горка авыл җирлеге чиге Ширәмәт авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 34 нче тоташу ноктасыннан алып 50 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м «Зәй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Болгар участок урманчылыгындагы 32 нче урман кварталы буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 800 м әлеге урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары, Ширәмәт авылына килә торган автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 32 нче, 31 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м төньяк-көнбатышка таба, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 100 м 31 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 31 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, төньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык

ясап, 31 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,6 км бара, аннары, Чистай – Түбән Кама автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньякка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 31 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 800 м бара, аннары 29 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 800 м төньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 1,6 км 30 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м 30 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м бара, шуннан соң 30 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 500 м, төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 50 м, буаны кисеп үтеп, чүплекнең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м һәм 30 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м 33 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Түбән Кама муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
12 нче кушымта

**Түбән Кама муниципаль районының «Макаровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Макаровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Макаровка авыл җирлеге Түбән Уратма, Сосновка, Ширәмәт авыл җирлекләре, Зәй һәм Яңа Чишмә муниципаль районнары белән чиктәш.

Макаровка авыл җирлеге чиге Ширәмәт авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Макаровка, Ширәмәт авыл җирлекләре һәм Яңа Чишмә муниципаль районы чикләре тоташкан урында Оша

авылыннан 4,3 км көньякта урнашкан 36 нчы тоташу ноктасыннан алып 3,1 км төньякка таба «Зәй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Өргәнчә участок урманчылыгындагы 52, 39, 26 нчы урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң 550 м көнчыгышка таба 26 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап бара, аннары 800 м төньяк-көнчыгышка таба «Зәй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Болгар участок урманчылыгындагы 87 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Оша елгасын кисеп үтеп, 50 м 86 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м 86 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 150 м 104 нче урман кварталындагы аерымланган кишәрлекнең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, файдаланылмый торган тимер юлына һәм профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаларны кисеп үтеп, 86, 85, 80 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 2,6 км Макаровка, Ширәмәт һәм Түбән Уратма авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Оша авылыннан 3,1 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 35 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Макаровка авыл җирлеге чиге Түбән Уратма авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 35 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 250 м «Зәй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Болгар участок урманчылыгындагы 80 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 50 м, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 450 м бара, аннары инеш агымы буйлап аска таба 250 м кибеп баручы инеш белән кушылганчы уза, шуннан соң аның агымы буйлап өскә таба 150 м бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 50 м профильле автомобиль юлы буйлап уза, шуннан соң 72, 81, 89 нчы урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап 2,7 км бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 3,3 км файдаланылмый торган тимер юлы буйлап бара, шуннан соң 92 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 30 м, көньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 300 м бара, аннары 106 нчы урман кварталындагы аерымланган кишәрлекнең көнбатыш чиге буйлап 800 м көньякка таба уза, шуннан соң «Зәй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ямаши участок урманчылыгындагы 9 нчы, 10 нчы урман кварталларының төньяк чиге буйлап көнчыгышка таба 1,9 км бара, аннары, файдаланылмый торган тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл

хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 150 м, 10 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м уза, шуннан соң, файдаланылмый торган тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,3 км төньяк-көнчыгышка таба кибеп баручы инешкә кадәр бара, әлеге инеш агымы буйлап аска таба 3,4 км, Зәй — Югары Уратма — Ширәмәт автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, шушы инеш агымы буйлап 3,4 км аска таба уза, аннары Уратма елгасы агымы буйлап өскә таба 100 м аңа инеш койган җиргә кадәр бара, шуннан соң аның агымы буйлап өскә таба 1,9 км уза, аннары, кибеп баручы инешне берничә тапкыр кисеп үтеп, сынык сызык ясап, көнчыгышка таба 1,2 км Макаровка, Түбән Уратма авыл җирлекләре һәм Зәй муниципаль районы чикләре тоташкан урында Макаровка авылыннан 2,6 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 37 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Макаровка авыл җирлеге чиге Зәй муниципаль районы белән чиктәш җирдә 37 нче тоташу ноктасыннан алып Түбән Кама муниципаль районы чиге буйлап Макаровка, Сосновка авыл җирлекләре һәм Зәй муниципаль районы чикләре тоташкан урында Тетвель авылыннан 4,9 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 38 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Макаровка авыл җирлеге чиге Сосновка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 38 нче тоташу ноктасыннан алып 550 м көньяк-көнбатышка таба «Зәй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ямаши участок урманчылыгындагы 55 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң, Югары Уратма — Благодатный автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасы буйлап, Тетвель елгасын һәм яр буендагы агач-куак массивын кисеп үтеп, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 200 м 110 нчы урман кварталындагы аерымланган кишәрлекнең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м уза, шуннан соң 110 нчы урман кварталындагы аерымланган кишәрлекнең көньяк чиге буйлап көнчыгышка таба 400 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м уза, аннары 111 нче урман кварталындагы аерымланган кишәрлекнең төньяк чиге буйлап 100 м, агач-куак массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 850 м, 111 нче урман кварталындагы аерымланган кишәрлекнең төньяк чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м бара, 111 нче урман кварталындагы аерымланган кишәрлекнең төньяк чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м уза, аннары 27 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-

көнбатышка таба 1,4 км, яр буендагы агач-куак массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м инешкә кадәр бара, инеш агымы буйлап аска таба 150 м Иске елгасына кушылганчы уза, шуннан соң әлеге елга агымы буйлап аска таба 450 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м төньяк-көнбатышка таба, 400 м көньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң 110 нчы урман кварталындагы аерымланган кишәрлекнең көнчыгыш чиге буйлап көньякка таба 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м һәм 110 нчы урман кварталындагы аерымланган кишәрлекнең көнчыгыш чиге буйлап 100 м бара, аннары, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 950 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 110 нчы урман кварталындагы аерымланган кишәрлекнең көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап 200 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,6 км көньяк-көнбатышка таба, 900 м төньяк-көнбатышка таба Макаровка, Сосновка авыл җирлекләре һәм Яңа Чишмә муниципаль районы чикләре тоташкан урында Володарский поселогыннан 3,1 км көньяк-көнбатышта урнашкан 40 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Макаровка авыл җирлеге чиге Яңа Чишмә муниципаль районы белән чиктәш җирдә 40 нчы тоташу ноктасыннан алып Түбән Кама муниципаль районы чиге буйлап 36 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Түбән Кама муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
13 нче кушымта

## Түбән Кама муниципаль районының «Түбән Уратма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Түбән Уратма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Түбән Уратма авыл җирлеге Кызыл Чапчак, Майская Горка, Макаровка, Ширәмәт авыл җирлекләре һәм Зәй муниципаль районы белән чиктәш.

Түбән Уратма авыл җирлеге чиге Ширәмәт авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Түбән Уратма, Ширәмәт һәм Макаровка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Оша авылыннан 3,1 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 35 нче тоташу ноктасыннан алып 100 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,4 км көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 1,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 700 м Ширәмәт – Кармалы автомобиль юлы буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 650 м, төньяк-көнчыгышка таба 50 м уза, шуннан соң инеш агымы буйлап аска таба 4,3 км бара, аннары, инешнең текә ярын кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 950 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 600 м Зәй – Югары Уратма – Ширәмәт автомобиль юлы буйлап уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 200 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м җитештерү мәйданының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньякка таба 150 м күмәк бакчаларның көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 200 м чокырның көнчыгыш чиге буйлап Уратма елгасына кадәр уза, 600 м шушы елга агымы буйлап аска таба бара, аннары 10 м төньяк-көнчыгышка таба агач-куак массивы буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Түбән Уратма, Ширәмәт һәм Майская Горка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ширәмәт авылыннан 500 м көнчыгышта Уратма елгасында урнашкан 34 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Түбән Уратма авыл җирлеге чиге Майская Горка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Түбән Уратма, Майская Горка һәм Кызыл Чапчак авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Олы Аты авылыннан 2,1 км көньяк-көнбатышта урнашкан 31 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 100 м «Зәй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Болгар участок урманчылыгындагы 39 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап, инешне кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 39 нчы, 38 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш, төньяк чикләре буйлап 1,1 км уза, аннары төньякка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре

буйлап, 150 м 38 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м һәм 38 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 100 м бара, шуннан соң көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,6 км 38, 37, 36 нчы урман кварталларының төньяк чиге буйлап уза, аннары 36 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 550 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м бара, сынык сызык ясап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 36, 41, 40 нчы урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап 3,0 км уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,2 км 40 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 45 нче, 51 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап көньякка таба 700 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 150 м, төньяк-көнбатышка таба 150 м, көньяк-көнбатышка таба 350 м, текә ярның төньяк чиге буйлап 550 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 500 м, төньяк-көнбатышка таба 200 м уза, 102 нче урман кварталындагы аерымланган кишәрлекнең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, 102 нче урман кварталындагы аерымланган кишәрлекнең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көнбатышка таба 102 нче урман кварталындагы аерымланган кишәрлекнең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 300 м уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 102 нче урман кварталындагы аерымланган кишәрлекнең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньякка таба 50 м, төньяк-көнбатышка таба 150 м уза, шуннан соң 33 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 600 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м бара, аннары Уратма елгасы агымы буйлап аска таба 1,2 км уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 1,8 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м 32 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м 32 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, Уратма елгасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, аннары әлеге елга агымы буйлап аска таба 1,4 км 34 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Түбән Уратма авыл җирлеге чиге Кызыл Чапчак авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Түбән Уратма, Кызыл Чапчак авыл җирлекләре һәм Зәй муниципаль районы чикләре тоташкан урында Югары Чаллы авылыннан 2,2 км көньякта урнаш-

кан 30 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м «Зәй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Болгар участок урманчылыгындагы 50 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 700 м 50 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м 50 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м уза, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 50 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 100 м, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 50 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап бара, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 50 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м һәм 49 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 550 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м, 49 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 400 м һәм төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 850 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба 100 м, төньяк-көнчыгышка таба 1,6 км уза, буаны кисеп үтеп, 44 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 150 м бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 39 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, төньякка таба 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м буаның сулъяк яры буйлап, 100 м 39 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 31 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Түбән Уратма авыл җирлеге чиге Зәй муниципаль районы белән чиктәш җирдә 30 нчы тоташу ноктасыннан алып Түбән Кама муниципаль районы чиге буйлап Түбән Уратма, Макаровка авыл җирлекләре һәм Зәй муниципаль районы чикләре тоташкан урында Макаровка авылыннан 2,6 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 37 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Түбән Уратма авыл җирлеге чиге Макаровка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 35 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 250 м «Зәй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Болгар участок урманчылыгындагы 80 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 50 м, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 450 м бара, аннары инеш агымы буйлап аска таба 250 м кибеп баручы инеш белән кушылганчы уза, шуннан соң аның агымы буйлап өскә таба 150 м бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 50 м профильле автомобиль юлы буйлап уза, шуннан соң 72, 81, 89 нчы урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап

2,7 км бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 3,3 км файдаланылмый торган тимер юлы буйлап бара, шуннан соң 92 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 30 м, көньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 300 м бара, аннары 106 нчы урман кварталындагы аерымланган кишәрлекнең көнбатыш чиге буйлап 800 м көньякка таба уза, шуннан соң «Зәй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ямаши участок урманчылыгындагы 9 нчы, 10 нчы урман кварталларының төньяк чиге буйлап көнчыгышка таба 1,9 км бара, аннары, файдаланылмый торган тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 150 м, 10 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м уза, шуннан соң, файдаланылмый торган тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,3 км төньяк-көнчыгышка таба кибеп баручы инешкә кадәр бара, әлеге инеш агымы буйлап аска таба 3,4 км, Зәй – Югары Уратма – Ширәмәт автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, шушы инеш агымы буйлап 3,4 км аска таба уза, аннары Уратма елгасы агымы буйлап өскә таба 100 м аңа инеш койган җиргә кадәр бара, шуннан соң аның агымы буйлап өскә таба 1,9 км уза, аннары, кибеп баручы инешне берничә тапкыр кисеп үтеп, сынык сызык ясап, көнчыгышка таба 1,2 км 37 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Түбән Кама муниципаль районы»<br>муниципаль берәмлегенең һәм аның<br>составындагы муниципаль берәмлекләрнең<br>территорияләре чикләрен билгеләү<br>һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>14 нче кушымта

**Түбән Кама муниципаль районының «Прости авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Прости авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Прости авыл җирлеге «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге, Красный Ключ авыл җирлеге, Алабуга һәм Тукай муниципаль районнары белән чиктәш.

Прости авыл җирлеге чиге Красный Ключ авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Прости, Красный Ключ авыл җирлекләре һәм Алабуга муниципаль районы чикләре тоташкан урында Красный Ключ поселогыннан 2,7 км көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=463815,04, Y=2289998,28 координаталы 44 нче тоташу ноктасыннан алып 250 м көньякка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап Прости, Красный Ключ авыл җирлекләре һәм «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Красный Ключ поселогыннан 2,7 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 43 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Прости авыл җирлеге чиге Алабуга муниципаль районы белән чиктәш җирдә 44 нче тоташу ноктасыннан алып Түбән Кама муниципаль районы чиге буйлап Прости авыл җирлеге, Алабуга һәм Тукай муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Прости авылыннан 8,3 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 20 нче (62 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Прости авыл җирлеге чиге Тукай муниципаль районы белән чиктәш җирдә 20 нче (62 нче) тоташу ноктасыннан алып Түбән Кама муниципаль районы чиге буйлап Прости авыл җирлеге, «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Тукай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Прости авылыннан 5,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 21 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Прости авыл җирлеге чиге «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 43 нче тоташу ноктасыннан алып көнчыгышка таба 1,9 км Комлык утравының төньяк чиге буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 600 м Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап бара, шуннан соң, инешләрне һәм агач-куак массивларын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,0 км көньякка таба, инешләрне һәм яр буендагы агач-куак полосаларын кисеп үтеп, 1,2 км көньяк-көнбатышка таба, инешләрне кисеп үтеп, 150 м сазлык буйлап, 750 м Түбән Кама – Соболеково автомобиль юлы буйлап уза, аннары, инешләрне һәм яр буендагы агач-куак массивларын берничә тапкыр кисеп үтеп, сынык сызык ясап, көньякка таба 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң инеш агымы буйлап 50 м өскә таба уза, аннары, инешләрне берничә тапкыр кисеп үтеп, сынык сызык ясап, көньякка таба 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, гараж кооперативының төньяк, көнчыгыш һәм көньяк

чикләре буйлап 1,4 км көньяк-көнбатышка таба, 50 м профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң, чокырларны, профильле автомобиль юлына һәм Түбән Кама – Прости автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаларны, инешләрне, агач-куак һәм урман массивларын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 6,9 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Түбән Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Биклән участок урманчылыгындагы 114 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 600 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, 114 нче урман кварталындагы аерымланган кишәрлекнең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м һәм төньяк-көнчыгышка таба көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 550 м бара, шуннан соң 43 нче урман кварталы буйлап 450 м көнчыгышка таба 21 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Түбән Кама муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
15 нче кушымта

## Түбән Кама муниципаль районының «Сосновка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Сосновка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Сосновка авыл җирлеге Макаровка авыл җирлеге, Әлмәт, Зәй һәм Яңа Чишмә муниципаль районнары белән чиктәш.

Сосновка авыл җирлеге чиге Макаровка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Сосновка, Макаровка авыл җирлекләре һәм Зәй муниципаль районы чикләре тоташкан урында Тетвель авылыннан 4,9 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 38 нче тоташу ноктасыннан алып 550 м көньяк-көнбатышка таба «Зәй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ямаши участок урманчылыгындагы 55 нче урман кварталының

